«Мин хәзер транспортка утырырга куркам»

«ШК» журналисты Санкт-Петербург метросында шартлау вакытында шунда булган татарстанлылар белән аралашты.

2-3 БИТ

Күңелең төшмәсен!

Психотерапевт Гомәр Зыятдинов: «Кеше ике атнадан артык хәлсез, канәгатьсез икән, димәк, аңарда –депрессия. Әгәр бер көн начар булып, ике көн яхшы кәеф белән йөри икән, бу бернинди дә депрессия түгел, күңел төшенкелеге генә».

13 БИТ

1990 ЕЛДАН БИРЛЕ ЧЫГА

Шәһри КАЗАН

татмедиа

Пәнҗешәмбе | 6.04.2017 | № 36 (5798) www.shahrikazan.com

ТАТАРСТАН БАШКАЛАСЫНЫҢ КӨНДӘЛЕК ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ҺӘМ МӘДӘНИ ГАЗЕТАСЫ

ГЕРМАНИЯГӘ БАРАСЫҢ КИЛӘМЕ? АВЫЛГА КАЙТ!

Яшь фермерлар Раилә белән Илдар Гарифуллиннар гаиләсенең бер хыялы бар: авыл башында гына урнашкан шәхси кырларында мегаферма төземәкче алар. Сыерлар иректә йөреячәк, савым вакыты җиткәч, урыннарына үзләре килеп басачак. Сөтләре дә кимеми, көненә өчәр тапкыр савып булачак. Ә ферма тирәсендә туристлык комплексы җәеләчәк... Әкият, дисезме? Бер дә алай түгел, яшь гаилә мондый ферманы Германиядән күреп кайткан.

7 БИТ

П2430 Атналык (пәнҗешәмбе)

1 айга 69 сум 31 тиен
3 айга 207 сум 93 тиен
6 айга 415 сум 86 тиен

Ташламалы бәядән язылып кал!

11-21 май, 2017
Абунәче декадасы

П2395 Көндәлек (сишәмбе, пәнҗешәмбе, җомга)

142 сум 38 тиен 1 айга
427 сум 14 тиен 3 айга
854 сум 28 тиен 6 айга

Реклама

РЕСПУБЛИКАДА

ӘЛМӘТ

Әлмәт шәһәрендә Ленин урамындагы бер йортта яшәүчеләр: «Подъездда матур булса, үзебезгә дә рәхәт», – дигән фикердә. Шуңа да подъезддагы һәр каттагы тәрәзә төбенә чәчәкләр утыртканнар, аларга су сибеп, төпләрен йомшартып торалар икән.

КУКМАРА

Кукмарада мәктәп укучылары экология акциясенә кушылганнар. Укытучылар балаларга табигатьне саклау, кошлар турында сыйныф сәгатьләре, экологик дәресләр уздырганнар, рәсемнәр конкурсы оештырылган. Укучылар исә әти-әниләре, сыйныф җитәкчеләре белән бергә 350 сыерчык оясы ясаган.

ЛАЕШ

Лаеш мәктәбе укучылары агач утыртырга әзерләнә. «Лаеш урманчылыгы» оешмасыннан белгечләр килеп, аларга үсентеләрне дөрес итеп утырту тәртибе, агачлар турында кызыклы мәгълүматлар җиткергәннәр. Урманчылык белән бәйле һөнәрләр турында да сөйләгәннәр.

МАМАДЫШ

Мамадышта «Мөнәҗәтләр» бәйгесе узган. Әлеге чараны уздырган «Ак калфак» оешмасы һәр катнашучыга үз куллары белән кульяулык яки калфак чигүне дә шарт итеп куйган. Бәйгедә шулай ук «Исем кушу» йоласы да күрсәтелгән.

ЧИРМЕШӘН

Әмир авылында хәзердән үк Сабан туена әзерләнә башлаганнар. Авыл егетләре колга тотып, гармуннар уйнап, һәр йортка кереп бирнә җыйган. Оста киленнәр чиккән сөлгеләр, кульяулыклар Сабан туе уеннарында җиңүчеләргә кадерле бүләк булачак.

Яңалыклар район газеталары сайтларыннан алынды.

«Мин хәзер транспортка

Шартлауга кадәр һәм шартлаудан соң. Санкт-Петербург бүген шулай яши. Тормыш кисәк кенә «аңа хәтле» һәм «аннан соң» дигән төшенчәләргә бүленде. Дистәләгән кешенең ишеген шакыган кайгы ил фаҗигасенә әйләнде.

Эльвира МОЗАФФАР

Метрода шартлау вакытында шул ук вагонда Чаллы кызы Анна Стужина да булган. Бу хакта Татарстан Республикасының Санкт-Петербург һәм Ленинград өлкәсендәге тулы вәкаләтле вәкиле Ренат Вәлиуллин хәбәр итте. 21 яшьлек Анна хәзер Мариин хастаханәсендә дәвалана. Табиблар аның хәлен тотрыклы дип бәяли, янында апасы тора.

«ШК» журналисты исә Аннаның үзе белән элемтәгә керде.

Метрода фаҗига буласы көнне ул өенә кайтып бара торган булган.

– Метро ишегенә каршы баскан идем. Кинәт ут кабынып алгандай булды, шартлау тавышы ишетелде. Мин битемне кулым белән капладым. Поезд баруын дәвам итте. Туктагач, кем кайдан чыгарга ашыкты. Мин метро ишегендәге тәрәзә аша чыктым. Кулларым пеште. Шөкер, метродагы шартлау корбаннары арасында танышларым, якыннарым юк, – ди Анна.

Ул Көнчыгыш институтының икенче курсында, япон телен өйрәнгән. Әмма февраль аеннан лекцияләргә йөрми башлаган, билгеле бер сәбәпләр аркасында, белгечлеген алыштырырга уйлаган. Хәзер Санкт-Петербург дәүләт мәдәният институтына укырга керергә хыяллана. Фаҗигагә кадәр Бердәм дәүләт имтиханнарына әзерләнеп йөргән. Хастаханәдән чыккач, Чаллыга кайтып килергә җыена. Анда аның туганнары яши икән. Әтиәнисе башка шәһәрдә яши.

– Мин хәзер транспортка утырырга бөтенләй куркам, – ди Анна.

Метродагы шартлау шаһиты булган, зыян күргәннәргә үзе дә ярдәм итәргә тырышкан Аксубай кызы Евгения Краснова бүген дә шок хәлендә. «Дарулар эчеп, психологлар белән сөйләшеп кенә рәтләнәм, бу вакыйгаларны искә алсам да куркыныч», – ди икән үзе. Куркыныч истәлекләрен кабат яңартырга теләмәдек, бу хакта Евгенияне якыннан белгән Аксубай район газетасы журналисты Людмила Жаренова белән сөйләштек.

– 31 март көнне якташыбыз Санкт-Петербургка туганнарына кунакка киткән иде. Фаҗига буласы көнне «Технология институты» станциясендә апасы, дуслары белән эскалаторда басып төшкән фотосын да социаль челтәргә элгән иде. Метро станциясендә ишегә каерылган, тәрәзәләре ватылып беткән вагонны күреп тетрәнгәннәр, – дип сөйли Людмила.

«Вагон төтен эчендә, кешеләр кайсы тәрәзәдән, кайберләре ишектән сикерә, барысы да кычкыра, ашыга, этешә иде», – дип сөйләгән Женя. Кыз автомәктәптә өйрәнгәннәрен искә төшерел, тиз арада зыян күрүчеләргә ярдәмгә ашыккан, яраланган ир-атның кулына чәч резинкасы ярдәмендә жгут салган.

«Минем бәхетем бар икән, нәкъ менә «Сенная площадь» станциясеннән утырып китәргә теләгән идем, ярый әле тагын азрак йөреп килергә уйладым. Үлгән кешеләрне метро вагоныннан чыгарганда кичергән хисләремне белсәгез… Коточкыч… Хәзер йоклый да алмыйм, транспортка кергән, чыккан һәр кешене җентекләп карыйм, урамда кеше күп җыелса да куркам», – дип хисләре белән уртаклашкан Женя.

Людмила Евгенияне электән актив кыз дип сөйли. Ул районда «Яшь гвардия» иҗтимагый оешмасын җитәкләгән, волонтер булып эшләгән.

Метродагы шартлау 14 кешенең гомерен өзде, 49 кеше бүгенге көндә хастаханәләрдә дәвалана. Әлеге фаҗига теракт дип бәяләнде. Санкт-Петербургта өч көнлек матәм игълан ителде.

Кичә премьер-министр Дмитрий Медведев терактта зыян күрүчеләргә һәм һәлак булганнарның гаиләләренә матди ярдәм күрсәтү турындагы күрсәтмәгә кул куйды, дип хәбәр итте Россия хөкүмәтенең матбугат хезмәте.

Россия хөкүмәтенең резерв фондыннан һәлак булганнарның гаиләләренә – берәр миллион, сәламәтлекләренә зур яки уртача зыян алучыларга – 400 мең сум, җиңелчә зыян күрүчеләргә – 200 мең сум; шулай ук күмү чыгымнарын каплар өчен – барлыгы 50 миллион сум акча бүленеп биреләчәк.

Тикшерүчеләр террорчының исемен дә атады: ул – 1995 елгы кыргыз кешесе Әкбәрҗан Җәлилов. Икенче станциядә шартлаткычны да ул куеп калдырган, диләр.

Евгениянең Петербург метросында фаҗигагә кадәр төшкән фотосы.

vk.com

Шәһәр кәефе

ФӘРИТ НУРМӨХӘММӘТОВ,
журналист:

– Казанда, гомумән караганда, урам юллары төзек, әлбәттә. Ләкин шәһәр читендәге урамнарның тәртипкә китерәсе бар әле. Болакта да унбишәр сантиметрлы чокырлар барлыкка килде. Машинамда даими йөргәч, мин аларны хәтерлим, урап узам. Башка төбәкләрдән килгән кешеләр машиналарының тәгәрмәчен дә кәерттерып чыгарырга мөмкиннәр. Сазлы чокырга асфальт яки бетон агызмасыннар иде, катнашма ябышмый бит.

ЛИЛИЯ ГОССАМЕТДИНОВА,
студент:

– Югары уку йортында икътисадчы белгечлеге үзләштерәм. Икенче курста хәзер. Санкт-Петербургтагы террорлык актында һәлак булган кешеләрне бик кызганам. Төп хыялым – укуны әйбәт кенә тәмамлау һәм Казанда эшкә урнашу. Чистай кызы мин үзем. Әти-әни: «Сез бәхетлеләр, Чулман елгасы аша күпер төзелде. Казанга сәгать эчендә барып җитәсез», – ди.

РӘМЗИЯ ЧИТНИЕВА,
хезмәткәр:

– Казанга 1973 елда унд үрт яшемдә килгән идем. Җитен комбинатында эшләдем. «Горводзеленхоз» трестында хезмәт куйдым. Трест җитәкчесе Роза Җәббарова коллективка бик игътибарлы, аны гел рәхмәт хисләрендә телгә алам. Авиатөзелеш районында ТЭЦ урамы белән Белинский урамы кисешкән урында, ягъни «Птичий рынок» янында автобус тукталышы ясасыннар иде.

ӘЛФИЯ ИЛЬЯСОВА,
рәссам:

– Казан – имин, мәгърур шәһәр, биредә тууым белән горурланам. Язны сагынып көтеп алдым, рассадалар утырттым. Балконым җәй буе шау чәчәктә булачак. Узып баручылар да сокланып узар, әлбәттә. Кызым айти технологияләр буенча Иннополиста беренче курста укый. Аның янына барып йөрибез. Тиздән ул да каникулга кайтыр дип көтәм. Җәй көне бөтен кеше көч тупласын, сәламәтлеген ныгытсын дип телим.

ШАМИЛ ГАРИФУЛЛИН,
пенсионер:

– Күп еллар «Татфото» берләшмәсендә эшләдем. Чуйков урамында «Солнышко кафесы» дигән тукталыш бар. Әлеге кафеның беткәненә ун ел инде. Аны «Охотник и рыболов» дип үзгәртергә кирәк, чөнки тукталыш нәкъ шул исемдәге кибет каршында. Гагарин урамындагы «Октябрьский» тукталышы «Яңа Савин районы прокуратурасы» дип үзгәртелсә, отышлырак булыр иде.

утырырга куркам»

rbc.ru

vk.com

Әлеге фаҗига ил кайгысына әйләнде. Россия халкын тагын бер зур фаҗига тетрәндерде һәм шул тетрәнү аша берләштерде. Петербург халкының тирән кайгысын ил генә түгел, дөнья уртаклаша. Россия Президенты исеменә төрле илләр башлыкларыннан кайгы уртаклашу телеграммалары килде.

Казанда шул ук көнне Петербург урамына чәчәкләр китерә башладылар. Метро станцияләрендә чәчәкләр салу, тукталышларга «Питер, без синең белән» дигән плакатлар белән чыгу икенче, өченче көнне дә дәвам итте.

САН

*Татарстанда **2017** елда төзелеш материаллары җитештерә торган **6** завод ачарга җыеналар. Предприятиеләрнең берсе – Arch-Skin оешмасы елына **3** миллион квадрат метрга кадәр куәт белән керамик плитәләр җитештерер дип ниятләнә.*

ТОП – 3

БИШКӘК шәһәрендә сатуга электрон намазлык чыккан. Уникаль намазлык датчиклар белән җиһазландырылган. Алар намаз укыганда рәкәгатьләрнең санында буташмаска, намаз вакытында бөтен хәрәкәтләрне дөрес үтәргә ярдәм итәчәк. Электрон намазлыкка намаз эчендә укыла торган сүрәләр һәм догалар тыңларга мөмкинлек бирә торган аудиоплеер да урнаштырылган. Намазлыкны төрле яшьтәге ир-атлар һәм хатын-кызлар өчен дә көйләп, җайлап була, дип хәбәр итә muslim.kz.

ТАТАРСТАНДА Бердәм дәүләт имтиханнарын тапшыру вакытлары билгеле булды. Имтиханнарны вакытыннан алда тапшыру этабы 23 марттан ук башланган иде, 14 апрельгә кадәр дәвам итәчәк. Анда Татарстаннан меңнән артык укучы катнаша. Бу – узган елдагыга караганда, өч тапкырга артыграк. Төп этап исә 29 майдан 1 июльгә кадәр узачак. Аны 15 меңгә якын кеше тапшырачак. Укучылар өчен рус теле һәм математикадан имтихан мәҗбүри булып саналса, теләк белән сайланган фәннәр арасында җәмгыять белеме, физика, биология һәм инглиз теле популяр икән.

КАЗАНДА төрмәдән чыгучылар өчен күп функцияле тернәкләндерү үзәге булдырырга ниятлиләр. Бу хакта «Социаль реабилитация һәм адаптация үзәге» автоном коммерцияле булмаган оешмасы генераль директоры Азат Гайнетдинов хәбәр итте. Хәзер 100 кешегә исәпләнгән бу үзәк өчен бина эзләү белән мәшгульләр. Биредә яшәр өчен тулай торак та булачак, элек хөкем ителгәннәргә җәмгыятькә яраклашу, өстәмә белем алу, эшкә урнашу мөмкинлеге дә тудырылачак. Медицина, юридик, психология ярдәме дә күрсәтеләчәк.

70 яшь уйландыра инде. Камал театры яныннан үтеп барам: чабата кадәр хәрефләр белән «70 яшь» дип язып куйганнар, ә мин бер күземне капладым да «яшь» дигән сүзгә карадым. Шулай яшь булып яшим әле.

Халык шагыйре Разил Вәлиевнең үзенең 70 яшьлегенә багышланган кичәсендә әйткән сүзләре

КҮРШЕЛӘРДӘ

Башкортстан

8 апрель көнне Стәрлетамакта сыр ярминкәсе узачак. Биредә Башкортстанның төрле районнарында җитештерелгән сыр продуктларын тәкъдим итәчәкләр. Әлеге чараның төп максаты – республика эшмәкәрләренең товарларын таныту. Халык мондый ярминкәләрне көтеп ала икән.

Мари Эл

Күптән түгел Беренче каналда «Мужское/Женское» тапшыруында 18 ел урманда, җәмгыятьтән аерылып яшәгән Сергей Войницкий язмышы турында сөйләделәр. Мари Элдан Ольга Бойкова да тапшыруга кунак булып килгән, ул Сергейнең хатыны булырга ризалык белдергән. Сергей исә Ольганы туган ягы Молдавиягә алып китәргә җыена, ди.

Чувашия

Чувашиядә халык күптән көткән аквапаркны ел азагына кадәр төзеп бетерергә вәгъдә итәләр. Ул «Амазония» этнокомплексында урнашыр дип көтелә.Әлеге ял итү урынында башка күңел ачу аттракционнары да булачак. Әйтик, «фонтаннар шәһәрчеген» республика көненә ачарга ниятлиләр.

14 яшең тулсын башта!

14 яше тулмаган балаларга социаль челтәрләрдән файдалануны тыярга. Ленинград өлкәсенең Законнар чыгару оешмасы депутатлары шундый тәкъдим белән чыккан, дип яза «Известия». Закон проекты буенча, социаль челтәрдә теркәлүченең паспорттагы мәгълүматларына игътибар бирәчәкләр.

izvestia.ru

Әгәр сервис җитәкчесе үсмернең яшен исәпкә алмый гына терки икән, аңа 100 меңнән 300 мең сумга кадәр штраф яный. Социаль челтәрләрдән кулланучыга исә закон бозганы, үзе турында мәгълүматларны яшергәне өчен 1 меңнән 3 мең сумга кадәр штраф салырга мөмкиннәр. Шулай ук бер кеше үз паспорты белән бер генә шәхси битен булдырырга тиеш дигән кагыйдә дә тәкъдим ителә.

КӨН КАДАГЫНА

Рамил ГАРИФУЛЛИН,
психолог, психотерапевт:

– Кайберәүләр, аеруча үсмерләр кешеләр сугышканны, кемнеңдер үлгәнен видеога төшерә дә социаль челтәрләргә куя. Алар өчен контент булдыру мөһим. Кешенең авыр кайгысын уртаклашу арткы планда кала. Әхлаксызлык, рухи тәрбиясезлек – куркыныч. Кайберәүләр виртуаль тормышта яши. Көне уеннар уйнап, компьютер төймәләренә басып уза. Ул шул виртуаль тормыштагы куркыныч уеннарны чынбарлыкка күчерүчегә әйләнә. Виртуаль тормыш белән чынбарлык арасындагы чикләр юыла. Яшьләрнең үз дөньяларына бикләнеп яшәве, каты бәгырьле булуларын мин «социаль юләрлек» дип саныйм. Интернет бәйлелек кичергән яшьләр, кызганычка, авыру.

Федерация Советында «Сату турында»гы законга үзгәрешләр кертүне күз уңында тоткан закон проекты эшләнгән. Кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм күрсәтү максатыннан әзерләнгән әлеге проект нигезендә, аның авторлары гипермаркетлар шимбә көнне кичке сәгать дүрткә кадәр, ә якшәмбедә бөтенләй эшләмәскә тиеш була. Атнаның башка көннәрендә дә зур сәүдә үзәкләренең ишекләре кичке тугызга кадәр генә ачык булачак. Шул рәвешле халык үзенә кирәкле товарны кечкенә кибетләр, базарлардан алырга тиеш була.

Илдар Мөхәммәтҗанов фотосы

Гипермаркетлар якшәмбе эшләмәячәк?

Сез ничек уйлыйсыз, әлеге чара кече һәм урта эшмәкәрлекне үстерергә ярдәм итәчәкме? Моңардан халык зыян күрмәячәкме?

Таһир Һадиев, Татарстан Дәүләт Советының Экология, табигатьтән файдалану, агросәнәгать һәм азык-төлек сәясәте комитеты рәисе:

– Сәүдә ул – бик катлаулы, четерекле өлкә. Закон проекты инициаторларының кече һәм урта эшмәкәрлеккә ярдәм итү теләген хуплыйм, әмма монда уйлап бетерәсе мәсьәләләр шактый. Моны кисәк кенә эшләп булмый. Бердән, сатып алучыларның хокукы кысылмасын, алар кайсы кибеткә, базарга барасын үзе сайлый. Аңа кайда уңайлы, шунда бара. Гипермаркетлар алар хәзер аралашу, күңел ачу урыны да булып тора бит әле. Икенчедән, фермерлар, җитештерүчеләр үзләренең товарларын әлеге дә баягы эре сәүдә челтәрләренә кертергә омтылсын. Көндәшлеккә сәләтлелек шунда күренә дә инде. Синең товарың алар куйган таләпләргә туры килергә һәм син аны ел дәвамында тәэмин итәргә тиеш.

Нәфил Гатауллин, Арча районы фермеры:

– Миңа калса, фермерлар өчен бу әйбәт булачак, халык базарга йөри башлар иде. Әмма гипермаркетларның аренда бәясен, хезмәт хакы түлисе бар, шуңа да бәяләрне арттырып куярга мөмкиннәр. Шунысы да бар: ярминкәләрдә, базарларда алыпсатарлар күп сата, аның файдасын фермерлар сизәрме икән?!

Фәрит Заһидуллин, шәхси эшмәкәр (Биектау районы):

– Базарда хәзер кеше кимеде, мин моны гипермаркетларның саны артудан күрәм. Әмма сыйфатлы, яхшы товар алырга теләгән билгеле бер категория кешеләр базарга килүен дәвам итә. Кая барасын халык үзе хәл итә инде, аны көчләп кибеткә куып кертеп яки базарга мәҗбүриләп җибәреп булмый. Базарның үз законнары…

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА.

Махсус билгесез йөрсәң – штраф

4 апрельдән юл йөрү кагыйдәләренә үзгәрешләр керде, дип хәбәр итә Татарстан буенча ЮХИДИ идарәсе матбугат үзәге. Хәзер стажлары ике елга тулмаган йөртүчеләргә икенче транспортны сөйрәтергә, мотоцикл, мопедларда пассажирлар йөртергә ярамаячак. Шулай ук аларның транспортларында тиешле өндәү билгесе дә булырга тиеш. Кирәк очракларда машиналарда «Балалар», «Ишетмәүче йөртүче», «Акрын йөри торган транспорт чарасы» һәм башка шундый махсус билгеләр кую да таләп ителәчәк. Билге булмаган очракта, 500 сум штраф яный. «Шипы» билгесенә килгәндә, хәзер сезонына карап, аны ябыштыру да мәҗбүри. Дөрес, ул сезон кайчан башлана икәнен ЮХИДИ хезмәткәрләре әле үзләре дә хәл итмәгәннәр булса кирәк. Юл йөрү кагыйдәләре җыелмасында бу хакта берни дә әйтелмәгән. Бары кышкы тәгәрмәчләр белән җәйге айларда (июнь, июль, август) йөрүне тыя торган закон гына гамәлдә. «Бу билгеләрне автомобиль җиһазлары сатыла торган махсус кибетләрдән, якын киләчәктә элемтә бүлекләреннән дә алырга мөмкин булачак», – дип ышандыра ЮХИДИ идарәсенең матбугат үзәге хезмәткәрләре.

«Газета түгел, шатлык таратучылар»

Үз һөнәре турында Арчадан хат ташучы Гөлшат Габдрахманова шулай ди. Ул «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте уздырган бәйгедә җиңү яулады. Ә бу атнада әлеге бәйге җиңүчеләрен Казанга чакырып бүләкләделәр.

Зөһрә САДЫЙКОВА

tatar-inform.ru

– Медицина училищесын тәмамлаганнан соң, Кошкар авылына фельдшер булып эшкә урнашкан идем. Бер елдан соң шушы ук авыл егете Илфатка кияүгә чыктым. Җиде ел матур тормыш иткәннән соң, ирем вафат булды. 28 яшемдә ике сабый бала белән тол калгач, районга барып эшләү мөмкинлеге булмады. Шул вакытта хат ташучыбыз лаеклы ялга киткән иде, миңа аның урынын тәкъдим иттеләр. Тормышны алып барырга, балаларны аякка бастырырга кирәк, шуңа күрә әлеге эшкә алынырга ризалаштым. Шулай итеп, 16 ел вакыт узып та киткән. Әлегә кадәр балаларны ялгызым тәрбиялим. Эшемне дә бик яратам, чөнки кешеләр белән аралашырга бик ошый. Хат ташучыларны кешеләргә шатлык таратучылар, дим. Чөнки без кешеләргә пенсия алып киләбез, яздырып алган газета-журналларын да зарыгып көтеп алалар. Аларның шат йөзләрен күргәч, үзебезгә дә күңелле. Шулардан ямь табып эшлибез. Аннан соң беренче һөнәрем буенча фельдшер булганлыктан, пенсия яки газета бирергә кергән җирдән уколын да кадап, кан басымнарын да үлчәп чыгам. Кызганыч, газета-журналларга бәяләр артып тора. Безнең төп укучыларыбыз – 45 яшьтән өлкәнрәкләр, пенсия яшендәгеләр. Кайберләре бик аз пенсия ала, әмма газетаны кулга тотып укырга өйрәнгән кеше бәяләр артуга карап кына язылмыйча калмый. Сигезәр-тугызар газета алдыручы гаиләләр бар. Арча районы халкы күбесенчә район газетасын, «Шәһри Казан», «Ватаным Татарстан», «Ирек мәйданы» газеталарын яратып укый. Киләчәктә дә безгә дә, сезгә дә эш булып, абунәчеләребез саны артып торсын иде дип телим, – диде безгә «Кечкенә шәһәрнең иң яхшы хат ташучысы» номинациясендә җиңү яулаган Гөлшат Габдрахманова.

«ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте «Татарстан почтасы» белән бергәлектә үткәргән бәйгенең төп шарты – район, шәһәр газеталарына язылучылар санын узган чордагыга караганда арттыру. Сүз уңаеннан, 2017 елның беренче яртыеллыгына «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте басмаларының тиражы 257,7 мең данә исәпләнә.

Җиңүчеләрне акционерлык җәмгыятенең генераль директоры Андрей Кузьмин котлады.

– Әлеге бәйгене җиденче тапкыр уздырабыз. Безнең өчен дә, халык өчен дә, аеруча авылларда, сездән дә якынрак кеше юк. Нинди генә һава торышы булуга карамастан, хат ташучылар үз эшләрен намус белән башкара. Сез психолог та, укытучы да, кирәк булса, фельдшер да әле. Безнең өчен иң мөһим күрсәткечләрнең берсе – абунәчеләр санын арттыру. Интернет, телевидение заманы, дибез. Әмма халык, традиция буенча, чынлап торып ышаныч яулаган бердәнбер мәгълумат чыганагын барыбер газеталарда күрә. Бездә төрле категория һәм төрле буын кешеләренә тәкъдим итәрлек матбугат чаралары бар. Газета-журналлар татар, рус, чуваш телләрендә чыга. Нәкъ менә сез безнең сәясәттә үткәргеч ролен үтисез дә инде. Шуңа күрә без дә сезнең йөзгә кызыллык китермәслек итеп эшләргә тырышырбыз. Иң актуаль, кызыклы, әчтәлекле һәм һәр телдә дә камил язылган мәгълүмат җиткерербез. Киләчәктә дә әлеге бәйгедә катнашырсыз дип өметләнеп калабыз, – диде ул.

«Почта элемтәсенең иң яхшы бүлеге» номинациясендә – Кама Тамагы районының Тенки авылы почта бүлеге, «Журналлар буенча иң яхшы тираж» номинациясендә – Чүпрәле районының Кече Чынлы авылы почта бүлеге, «Иң яхшы авыл хат ташучысы» – Рәмзия Кәлимуллина (Балтач районы, Шөңшеңәр авылы), «Иң яхшы шәһәр хат ташучысы» номинациясендә Юлия Морозова (Яшел Үзән шәһәре) җиңү яулады. Бәйгенең аерым җиңүчеләре – 15 мең, ә почта бүлекләре 30 мең сум күләмендә акчалата бүләкләнде.

Газетабызның даими укучысы 92 яшьлек Кәримә әби (үз үтенече буенча исемен үзгәртеп язам) редакциябезгә ярдәм сорап шалтыратты. «Улымны хастаханәгә урнаштырырга булышыгыз әле! Түзәр чамам калмады», – дип башлады ул сүзен. Баласына бер-бер хәл булгандыр дисәм, әби, бер көн булса да тынычлап яшәр идем, дип, улын җүләрләр йортына озатырга тели икән.

creu.ru

«Тынычлыкта яшәргә телим»

Эльвира МОЗАФФАР

Баштарак Кәримә әбинең сүзләрен 92 яшьлек карчыкның көйсезләнүе, саташуы дип кенә кабул иттем, әмма шалтыратулар, зарлар кабатлана торды. Мондый очраклар турында беренче генә ишетүем түгел. Бер авылдаш апа улын җирләгәннән соң: «Аллага шөкер», – дигән иде. Гомер буе үзен кыйнап яшәгән улының бакыйлыкка күчүенә артык борчылмады. Кызганыч, үзе дә тынычлыкта озак яши алмады, улы вафатыннан соң берничә атнадан гүр иясе булды. Кәримә әбинең дә хәлләре мөшкел. Елый-елый, үз тормышын сөйли.

– Иремнән дә гомер буе рәхәт күрмәдем, кызу канлы иде. Хыянәт итте. Шуны белеп, тешемне кысып яшәдем. Бердәнбер улым да атасына охшаган. Эчми, тартмый, ә менә атасы каны үзенекен итә. Дөрес, хатыннар белән чуалмый бугай чуалуын, тик менә туздырырга, җикерергә булдыра, – ди әби. – Без улым белән икәү генә яшибез. Бөтен пенсиямне ул алып бара. Кушсам, ашарыма алып кайта, аерым пешерәбез. Тынычлык ярата. Өйдә чебен очкан тавыш та ишетелмәскә тиеш. Хәтта телевизорны да тавышын басып, сурәтен генә карыйм. Радионы да колакчыннар киеп тыңлыйм. Әгәр ачуын чыгарсаң, кычкыра-кычкыра, башын идәнгә бәрәбәрә елый. Мин аңарда психик тайпылышлар бардыр дип уйлыйм. Кайчакта, үзе сизмәгәндә, боткасына тынычландыра торган дарулар да уып салам. Файдасы гына юк бугай. Ничек тә хастаханәгә урнаштырасы иде аны. Үзе бармый. Уколдан, ак халатлылардан курка. Бәлки, сәламәтлегенең начар икәнен күреп, инвалидлык та бирерләр иде үзенә. Киләчәктә яшәргә акчасы булыр иде ичмасам. Мин үлеп китсәм, бер тиенсез кала бит ул.

Укучыбыз сөйләвенчә, баштарак улы тыныч, сабыр булган. Өйләнгән, эшләгән. Тик менә әтисе үлгәннән соң, аны алыштырып куйганнармыни. Тиз кызып китүчәнгә әйләнгән, хатыны белән дә аерылышкан, эшеннән киткән.

– Мине картлар йортына куа. Синнән башка бер генә көн булса да тынычлап яшисе иде, ди. Мин исә, киресенчә, Аллаһыдан үземә тынычлык сорыйм. Кызганыч бала. Авыру инде ул. Шуңа миңа – әнисенә сүгенгәненә, кычкырганына рәнҗемим дә, – ди Кәримә әби.

Әңгәмәдәшемнең өендә булганыбыз, улын да күргәнебез бар. Психик тайпылышлы авыру буларак исәптә тормаган, карап торышка сәламәт кешене хастаханәгә илтеп ябу мөмкин дә, дөрес тә түгел, әлбәттә. Бу мәсьәләдә редакция хезмәткәрләре чарасыз.

СҮЗЕН-СҮЗГӘ

Нияз хәзрәт САБИРОВ, *Татарстан Диния нәзарәтенең пропаганда бүлеге җитәкчесе:*

– Баланың киләчәктә игелеген күрер өчен, аңа тиешле тәрбия бирергә, Аллаһка мәхәббәт тәрбияләргә кирәк. Балалар үз чиратында әти-әниләрен хөрмәт итәргә тиешләр, әниләрнең догаларыннан күп нәрсә тора. Әниләр балаларыннан риза булмаса, Аллаһы да ул балалардан риза булмый. Бала ул – әманәт. Һәр баланы Аллаһы бу дөньяга саф күңел белән китерә, ата-ананың бурычы – шул сафлыкны саклап калу, кечкенәдән сабыйга догалар өйрәтү, намазга бастыру, хәләл ризыклар белән генә тукландыру. Бала, губка кебек, бар нәрсәне сеңдерә. Балачагында күргән гамәлләр, әйтик, эти-әнисенең хәмер эчкәне, бәхәсләшүләре – барысы да киләчәк тормышында чагыла. Бу гаиләгә үзләре тирәсендәге мәчеттән бер хәзрәтне чакыртып әңгәмә уздырырга, вәгазьләр тыңларга киңәш итәм. Әби үзе дә намазларын, догаларын калдырмасын, Аллаһ барыбызга да тынычлык бирсен иде.

Элина ГАЛИУЛЛИНА, *авыр хәлдә калган хатын-кызларга ярдәм итә торган «Умиление» кризис үзәге җитәкчесе:*

– 92 яшенә җиткән әбинең бу рәвешле азапланып яшәве аяныч, әлбәттә. Картлар йортына урнашса, бәлки аңа тынычрак булыр иде? Шулай ук социаль яклау бүлекләренә мөрәҗәгать итәргә, үзенә социаль хезмәткәр билгеләүне сорарга була. Төрле социаль үзәкләрдә, шул исәптән безнең кризис үзәгендә дә өлкән кешеләргә ярдәм итүче волонтерлар бар. Әгәр улының әнисенә карата мөнәсәбәте тагын да начарланса, полиция хезмәткәрләрен, табибларны чакырырга була, әмма моны редакция хезмәкәткәрләре эшли алмый. Ә менә күршеләр тавыш ишетеп, тиешле хезмәтне кире тәртә ала.

Люция ЗАКИРҖАНОВА, *психолог:*

– Әлеге мәсьәләдә берьяклы гына җавап бирүе авыр. Мөгаен, бу гаиләдә мондый киеренке мөнәсәбәт күптәннән киләдер. Әни белән улы бер-берсенә түзеп яши. Һәрберсенең үз холкы, үз тайпылышлары. Әгәр бу ир-атка тавышлар, артык яктылык тискәре тәэсир итә икән, аның нерв белән бәйле авырулары булырга мөмкин. Гомумән, әнисенә дә, улына да психолог белән сөйләшергә, неврологка күренеп карарга киңәш итәр идем. Бу белгечләрдә бушлай да тикшеренергә була.

Шәһри Казан тыңлый

Тәкъдим, фикерләрегезне редакциябезгә **8 (843) 562-50-12**, **562-50-03** номерлары аша юллый аласыз. «Шәһри Казан» тыңлый» сәхифәсенең киләсе темасы инвалидлык алу сорауларына багышланачак. Сездән бу темага кагылышлы кызыксындырган сорауларыгызны көтеп калабыз.

СОРАУ-ҖАВАП

Җәй көне җылылык өчен түләнгән коммуналь хезмәтләргә субсидия алырга буламы?

Садыйковлар гаиләсе,
Казан.

Татарстанның Хезмәт, эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы белгечләре әйтүенчә, Министрлар кабинетының 738нче карары (2012 елның 27 сентябреннән) нигезендә, максатчан субсидия «Таттеплосбыт» җәмгыяте җылылык белән тәэмин итә торган Зәй, Казан, Чаллы, Түбән Кама шәһәрләрендә яшәүчеләргә каралган. Шулай ук Ютазы районының Урыссу шәһәр тибындагы бистәсе халкына да «Урыссу ГРЭС»ыннан файдаланган өчен ташламалар бирелә. Максатчан субсидия алу өчен алты ай саен гариза язарга, документлар тапшырырга кирәк. Субсидиянең күләме җылылык өчен түләнгән коммуналь хезмәтләр суммасыннан чыгып исәпләнә. Шул рәвешле җылылык бирү сезоны вакытында – гыйнвардан алып апрельгә һәм сентябрьдән декабрьгә кадәр – субсидияләр дә җәйге вакытка караганда күбрәк түләнә. Ә майдан августка кадәр җылылык өчен аз түләнгәнгә, субсидия дә азрак.

Без Марсель Сәлимҗанов урамындагы 12нче йортта яшибез. Подъезд алдындагы юллар бик начар. Асфальт чокырланып беткән. Яңгыр яуса, су җыела. Ишегалдындагы, подъезд каршындагы юлны кайчан ремонтларлар икән?

Гамбәрия Гафурова,
Казан.

Йортка хезмәт күрсәткән Вахитов районының идарәче компаниясе хезмәткәрләре аңлатуынча, Марсель Сәлимҗанов урамы 12 нче йорт подъездлары каршындагы юлларны төзекләндерү 2017 елгы планга кертелмәгән. Кызганыч, Вахитов белән Идел буе районы хакимиятендә дә өметле сүз әйтмәделәр. «Әгәр финанс мөмкинлекләре булса, әлеге йорт каршындагы юллар ремонтын 2018 елгы программага кертәчәкбез», – дип вәгъдә иттеләр районның торак сәясәте бүлегендә.

Мин – биш бала анасы. Фатир алу буенча чиратка баскан идек. Өч еллап көтсәк тә, һаман хәбәр юк. Бу мәсьәләдә ачыклык кертергә булышсагыз иде.

Фәридә Вәлиәхмәтова,
Арча районы, Кәчә авылы.

Арча районы башкарма комитетының инфраструктура бүлеге белгечләре әйтүенчә, Татарстан Министрлар кабинетының 326нчы (2008 елның 16 маеннан) карары нигезендә, торакка мохтаҗ күп балалы гаиләләргә дәүләттән ярдәм күрсәтелә. Шуның нигезендә, биш балалары булган Вәлиәхмәтовлар гаиләсе дә торак шартларын яхшыртырга хокуклы.

– 2014 елда бишенче баласы тугач, Фәридә Вәлиәхмәтова тиешле документларны җыеп, торак алу буенча чиратка басты. Бу программа районда уңышлы эшләп килә. Аны Татарстанның Төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалыгы министрлыгы контрольдә тота. Быел Арчада 2008 елда чиратка баскан күп балалы гаиләләргә торак бирелә. Вәлиәхмәтовлар 2014 елда чиратка бастылар, димәк, көтәргә кала. Чиратны берничек тә узып булмый. Закон нигезендә, программа буенча һәр кешегә 18 квадрат метр мәйдан тиеш. Бу очракта гаиләнең милкендә булган торагы да исәпкә алына. Вәлиәхмәтовларга килгәндә, аларга (әнисенә һәм биш баласына) 108 квадрат метр торак каралган. Аларның авылда 49,1 метр мәйдандагы торaклары бар. Шул рәвешле: 108-49,1= 58,9 квадрат метрлы фатирга өмет итә алалар. Гаиләгә торак чират нигезендә, бушлай бирeләчәк, – дип аңлатты белгечләр.

Чират, фатир буенча сорауларыгыз булса, Арчада Ирек мәйданы, 12нче йорт адресы буенча урнашкан район башкарма комитетының инфраструктура бүлегенә мөрәҗәгать итә аласыз. Анда сезгә барысын да җентекләп аңлатачаклар.

Кошларның да «урак өсте» була

Авыл урамы дигәч, еш кына күз алдына ямь-яшел чирәмдә сап-сары бәпкәләрен ияртикән ана каз килеп баса. Ни генә дисәң дә, бәпкәле казлар – авыл күрке, авыл яме шул. Кызганыч, бәпкә чыгарган ана казлар бик аз бүген. Бөтен авылның бер-ике хуҗалыгы гына мактана аладыр мондый булдыклы кошлар белән. Хәзер авыл халкының күбесе бәпкәләрне инкубатордан сатып алып үстерә бит. Тырыш казлар өчен март ахыры-апрель ае – кызу эш чоры. Аларның йомырка салып, аны 30 көн дәвамында кадерләп саклап, бәпкәләр чыгарасы бар.

Зөһрә САДЫЙКОВА

Зөлфия Зиннәтуллина, Мамадыш районы, Югары Кыерлы авылы, гомер буе каз асраучы:

– Йомырка салыр алдыннан, казның тукланууына игътибар итәм. Гыйнварга кадәр җиңелчә көрпәләр белән тотсам, аннан соң ипи ашата башлыйм, аз-азлап кына бодай, бәрәңге бирәм. Бодайны бик күп бирмәскә кушалар, чөнки йомырка кабыгы каты булып, бәпкәләргә чыкканда кыенлык тудырырга мөмкин. Каз хуҗасы әзерләгән ояны яратмый, шуңа күрә, гадәттә, билгеле бер урынга салам куям да ояны ата каз белән икәүләп коралар. Февральдә ата казның тавышы үзгәрә, шул вакытта ана каз да йомырка сала башлый. Йомырка салу вакыты табигатьтәге үзгәрешләр, көн озынлыгы белән бәйле, быел да нәкъ былтыргы вакытта сала башлады. Гадәттә, уникене сала иде, быел сигез генә булды. Моны башта җылы, аннары салкын көннәр тору белән бәйлим. 30 көн басканнан соң, май башында, Алла боерса, бәпкәләр чыгарга тиеш. Казыма 13 яшь инде, соңгы өч елда икешәр тапкыр баса башлады. Беренче басканы майда чыга, бераз түл җыйганнан соң, икенче катка йомырка салып, басарга утыра, ә ата каз ул вакытта бәпкәләрне үстерә. Гадәттә, икенче партия бәпкәләр июль башында чыга. Аннан соң шунысы бар: ана каз инкубатор бәпкәләрен үзенекеләргә кушканны яратмый, башта бик чукый, каты каурыйлар чыкканнан соң гына үз итә. Моннан тыш, ата казыбызның бер кызык гадәте бар, ана каз белән бәпкәләрне беренче тапкыр күргәндә, ул каңгылдый-каңгылдый «бии».

Равилә Кәлимуллина, Балтач районы:

– Казның йомырканы никадәр салуы ашатуга да бәйле. Йомырка сала башлаганчы тәрбиялим, икмәк бирәм. Әмма ризыкны артык күп тә бирергә ярамый, каз йомырканы күп салырга, әмма соңыннан утырмаска мөмкин. Гадәттә, бер сезонга, көнаралаш салып, 9-12 йомырка җыела. 25 йомырка салган вакытлары да булды. Ә аталану ихтималы – 50-80 процент. Йомырка салу өчен йорт казы 275 көндә өлгерә. Бу аның биш-алты айлык чорына туры килә. Индоурдәкләрем дә бар. Алар, казлар белән чагыштырганда, җылы яратучан. Каз йомыркада 30 көн утырса, индоурдәкләргә вакыт күбрәк кирәк. Аннан соң, борынлагач, аларның бәпкәләре барысы берьюлы чыгып бетә.

Ирек Хәмәдишин, Татарстан кошчылык фермерлары берләшмәсе җитәкчесе, Мөслим районы:

– Шәхси хуҗалыкта һәм фермаларда каз асрау күпкә аерыла. Без үз фермаларыбыздагы казларны фәнгә нигезләнеп карыйбыз, тукландырабыз, бәпкә чыгарабыз. Узган ел бер ана каз 43 йомырка салган иде. Быел бу күрсәткечне 44кә җиткерү бурычын куйдык. Безнең казлар салган йомыркаларның 80 проценттан артыгы бәпкәле. Йомырка каз астына салынгач, билгеле бер температура, дымлылык режимында 30 көн торырга тиеш. Бу көннәр аралыгында ул үзгәреп тора. Бәпкә чыгу өчен бу да төп шарт. Яңа технологияләр белән ясалган инкубаторларның мөмкинлеге бик зур. Шунысын да һәрвакыт истә тотарга кирәк: бәпкә чыгарсын өчен, казларны яратып карарга кирәк.

ПОЧТАДАН

Бармы берәр чара?!

«Иң зур бәхет – ана булу», «Көчле мәхәббәттән матур балалар туа», «Бала – гаилә көзгесе», диләр. Бәхетем дә, дәвамчым да, мактанырлык «гаилә көзгем» дә юк... Бәлки инде көчле мәхәббәт дигәне дә сүрелеп киләдер... Күңелдә бары үпкә, көнләшү һәм... кечкенә генә өмет дигәне.

Ирем белән гаилә корыуыма – 7 ел. 27дә генә кияүгә чыгуымны исәпләсәң, үз сабыен кулына алырга зарыккан хатынның яшен үзегез чамалагыз. Яшь бара, яшь арткан саен, балага мохтаҗлыгым да көчәя. Көндәлеге корт «соңга каласың, соңга калдың» дип, әрнегән ярага тозын каплап тондыра. Ул нишләсен, аның эше шул. Аңа кушылып дус-туганнар, күрешкән саен: «Юкмы соң әле?» – дип, яра өстендәге тозны «шап» иттереп бастырып куя. Сораганда, мыскыл иткәндәй, елмайган да булалар әле. Тимәгез, кагылмагыз болай да кимсенгән хатынның «аксак аягына»! Әгәр булса, әгәр көтсә, курыкмагыз, белми калмассыз. Сабый бит ул, бәхет бит ул, аны яшереп буламы?!

Сыйныфташ кызларның берәү генә түгел, ә ике, өченче балалары бар инде. Бергә җыелгач та, нәрсә турында сөйләшкәнне беләсезме? Әлбәттә, балалар. Кем нинди подгузник кигезә, нәрсә ашата, ничек аларга акча җиткерә... Ә мин... Күземне идәнгә төбәп, үпкә катыш: «Раббым, мин алардан киммени? Язсаңчы миңа да ана булу бәхетен татырга!» – дип ялварам. Шуңа соңгы елларда иптәш кызлар белән очрашулар да кимеде. Дөресрәге, очрашулар була, ләкин миннән башка.

Авылры танышларымның «кыз булсын иде, мәшәкате әз булыр» яисә «малай кирәк – нәсел дәвамчысы» дигәнрәк сүзләреннән дә эчемдә давыл улый. Шул максаттан, тузга язмаган ай календаре, кытай таблицалары, овуляция калькуляторы ярдәмендә балага узу көннәрен хисаплау да калмый. Кызларым, эх йолдызларым! Булсын иде! Бары булсын иде! Малаймы, кызмы, кара чәчлеме, коңгырт күзлеме, таза гәүдәлеме, кыска буйлымы – бары булсын гына иде! Кем булса да барыбер түгелмени?! Ул бит синеке, тик синеке – нарасыең, йөрәк парәң, Аллаһ биргән мәхәббәт җимешең. Сәламәт булсын иде, дип телисе генә бит. Булган саен, нәфес дигәне арта шул. Ә булмаганнар айдан-айга, елдан-елга, минем кебек, хәбәр көтә...

Яшермим, көнләшәм мин сездән, балалылардан. Ак көнчелек белән янам. «Авырлы икән», «бәбиләгән» кебек хәбәрләр дә йөрәгемә энә булып кадала. Миннән күпкә кече кызларның әни булулары турында ишетсәм, үземне ниндидер «җитешеп» бетмәгән, кимчелекле хатын итеп хис итәм. Аннан бер почмакка посып, бөтен әрнүемне күз яшьләре аша чыгарам. Башкаларныкы кебек «мәшәкатьле» тормыш телим үземә. Өең җыештырылмаган, бала уенчыкларына хәтта аяк абына, арлы-бирле сабыйларың йөгерешә, чыр-чу тавыш, һәркайсының телендә «әни», «әнием», «әнкәй»... Минем өчен моннан да олы бәхет булмас иде, мөгаен.

Бу, чара эзләмичә, зарланып кына утыра, дип уйламагыз. Ирем белән бармаган табиб, өшкерүче әби-бабай, укылмаган дога, ясамаган анализ, массаж-процедура, кадамаган укол калмады. Әҗәткә баттык, ләкин барысын да кыю үттек. Ахырда, машинаны сатып, ЭКО да ясатырга булдык. Табибларның сүзләреннән канатландык, «була, әлбәттә, була» дип көттек, өметләндек. Ләкин язмаса язмый икән шул: беренчесе дә, икенчесе дә нәтиҗәсез. Бары күңел генә ымсынды, төшенкелекнең төбенә төште.

Берләрегез: «Оныт, җибәр», икенчеләрегез: «Беткәнмени ятим бала», – диярсез. Киңәшне бирү генә җиңел икән шул. Бөтен җаның, тәнең, йөрәгең «бала» диеп алҗыганда, оныту мөмкин микән? Әле бит өмет дигәнең дә һаман саен «чеметеп» куя. Иремне дә, үземне дә башка җәфаламас өчен, хәзер инде барысын да бер Аллаһка тапшырдык. Бирүче дә, алучы да бары Ул бит.

Хис-кичерешләремне чит кешегә түгел, әниемә дә сөйләгәнем юк. Хәтта ирем белән дә бу турыда сөйләшмим. Кирәкми! Кирәкми чөнки кызгану! Миңа аңлау да җитә. Мин бит сәламәт, мин акылда, мин бары чарасыз...

Исемсез һәм баласыз хатын.

Адресым редакция өчен генә.

АБАУ!

Атна башында Бөгелмәдә өч яшьлек баласын дүртенче кат тәрәзәсеннән ташлаган бер хатын-кызга карата җинаять эше ачылган иде. Шөкер, бала исән калган, медицина хезмәткәрләре тиешле ярдәмне вакытында күрсәткән. 27 яшьлек ана кеше Лениногорск шәһәреннән булып чыккан, ул кулга алынган.

Баласын тәрәзәдән ташлаган

Кайбер интернет чыганаклар, мәхәббәт белән шөгыльләнергә комачаулаганы өчен, елаган баласыннан хатын шул рәвешле котылырга уйлаган, дип язса, Татарстан Тикшерү идарәсе җитәкчесенең өлкән ярдәмчесе Андрей Шептицкий бу мәсьәләгә ачыклык кертте.

– «Үтерергә җыену» маддәсе буенча, җинаять эше ачылды. Тикшерү нәтиҗәләреннән ачыкланганча, яшь ана якташы янына кунакка килгән. Дусты янында фатирда тагын ике ир-ат булган. Бергә кәеф-сафа корып утырганнан соң, ир-атларның берсе хатынга бәйләнә башлаган, көчләргә теләгән. Баланы йә үзеңне үтерәм, дип янаган. Фаразлар буенча, баласын коткарып калу өчен, хатын сабыйны тәрәзәдән ыргыткан. Сабый кар өеменә килеп төшеп, әллә ни каты имгәнмәгән, – дип аңлатты Андрей Шептицкий.

Бу вакыйгага буенча тикшерү дәвам итә.



Раилә Гарифуллина үз фермасында сыерлар сава.

Яшьләр Германиядә заманча техника сыный.

Германиягә барасың киләме? Авылга кайт!

Яшь фермерлар Раилә белән Илдар Гарифуллиннар гаиләсенең бер хыялы бар: авыл башында гына урнашкан шәхси кырларында мегаферма төземәкче алар. Сыерлар иректә йөреячәк, савым вакыты җиткәч, урыннарына үзләре килеп басачак. Сөтләре дә кимеми, көненә өчәр тапкыр савып булачак. Ә ферма тирәсендә туристлык комплексы җәеләчәк... Әкият, дисезме? Бер дә алай түгел, яшь гаилә мондый ферманы Германиядән күреп кайткан.

Алисә САБИРОВА

ЭШ АГАЧЫ БИРЕР ҖИМЕШ

Раилә белән Илдар гаилә тормышының башында, күп кенә яшьләр кебек, бәхетләрен калада – Чаллыда сынап карый. Ләкин авылның иркен болыннарына, саф һавасына ияләнгән егет белән кыз күңеле таш калага сыешмый. Ярты елдан соң туган яклары – Яңа Чишмә районының Шахмай авылына кайтып төпләнәләр.

– Мин мәктәптә инглиз теле укытучысы булып урнаштым. Берничә елдан укыту эшләре буенча директор урынбасарына күтәрелдем. Ирем авыл хуҗалыгы тармагында эшли. Тәвәккәлләп, үзебезнең гаилә фермасын булдырырга уйладык, – ди Раилә.

2011 елда зур өметләр белән салынган фермада бүген 30 баш сыер, 60ка якын үгез, бозау, кошкорт асрыйлар. Яшь гаиләгә әтиәнисе дә ярдәмгә килә.

– Беренче өч елы бик авыр булды. Башта ферманың чыгымнарын каплау өчен генә эшләдек дисәк тә була. Тора-бара аз-азлап керемен дә китерә башлады. Нәтиҗәсен күрмәсәк, шуның кадәр мал асрамас идек. Әле һаман фермабызны үстерәбез, яңа техника сатып алабыз, – ди хуҗабикә.

Гаиләнең көне иртәнге дүрттә башлана. Малларны бер кат карап кергәч, Раилә ханым мәктәпкә эшкә китә, төштән соң өчләр тирәсендә кайта да тагын маллар янына чыгып китә. Эш кичке унга кадәр дәвам итә. Дәүләт программаларына да кергәннәр. Фермага кадәр 300 метрлы юл салдырганнар. Авылдашлары өчен дә сезонлы эш урыннары булдыралар. Районның сөт комбинатына көненә 400-500 литр сөт тапшыралар. 2014 елда Гарифуллиннар хуҗалыгы республика буенча иң яхшы гаилә фермасы исеменә лаек була.

Бу тырыш гаилә Германиягә ничек барып чыккан соң? Татарстан Республикасының Аграр яшьләр берлеге ел саен авылда яшәүче, хезмәт итүче яшьләр арасында «Иң яхшы һөнәр иясе» дигән бәйге оештыра. Аның җиңүчеләре 10 мең сумлык сертификат һәм Германиянең Мюнхен шәһәренә стажировкага бару мөмкинлеге ота. Тырыш, актив гаилә буларак, Гарифуллиннарны район хакимияте бәйгегә тәкъдим иткән дә инде.

– Германиядә авыл хуҗалыгында эшләүчеләр иң бай кешеләр дип санала, шәһәрдә исә урта хәлләләр яши. Авыллары да шәһәрләренә караганда матуррак, – дип искә ала сәяхәтләрен Раилә. – Алардагы системаны безгә күчерсәк, авыл хуҗалыгы тармагында эшләү җиңелрәк булыр иде. Германиянең бер Аграр университеты эшчәнлеге белән таныштык. Уку йортының 200 сыердан торган үз фермасы бар, шунда практика уза. Илнең төрле алдынгы оешмалары яңа техникасын фермага бер елга бушка биреп тора. Шул рәвешле алар үзләренчә авыл хуҗалыгына да ярдәм итәләр, үз техникаларын да практикада сынап карыйлар. Бездә дә машина җитештерүче оешмалар шундый ярдәм күрсәтсә, яхшы булыр иде. Дәүләт аларга 2 процентлы кредит бирә, бездә исә аның проценты 16га кадәр җитәргә мөмкин, – ди Раилә.

ТӨГӘЛЛЕК КИРӘК

Менделеевск районында механизатор булып эшләүче Риналь Әхлиев тә 2015 елда алман авыл хуҗалыгы белән танышкан.

– Анда авыл хуҗалыгының 75 процентын фермерлар тәшкил итә. Һәр фермерга 40-50 гектар гына җир туры килә, бездәге кебек меңәр гектарлы кешеләр сирәк. Германиядә кеше хезмәте югары бәяләнә, зур хезмәт хаклары түләмәс өчен, фермерлар кырларында үзләре эшләргә тырыша. Күп әйбер роботлаштырылган. Аларның эшкә карашында да төгәллек чагыла. Төгәл үзенекен эшлиләр, төгәл үзенекен алалар. Эшне «тозлап» йөрү юк, – дип уртаклашты хис-кичерешләре белән Риналь.

Хезмәт хаклары да безнекеләрдән нык аерыла. Әйтик, шул ук механизатор Россиядә аена 15 мең сум алса, Германиядә 2 мең евро ала. Гаилә фермалары күбрәк мөгезле эре терлек асрый, терлекләргә ризык үстерә. Зур оешмалар җир эшкәртә. Риналь сүзләренчә, алманнар бер гектардан кимендә 35-110 центнер уңыш җыеп ала.

Риналь дә бу саннарны хыялда гына калдырмыйча, үз кырларында тормышка ашырмакчы. Абыйлары Динар, Эльнар белән өчесенә мең гектар җирләре бар. Рапс, кукуруз, арпа, бодай, солы үстерә алар. Хәзерге вакытта ферма төзекләндерәләр, ике атнадан анда Свердлау өлкәсеннән бозаулар кайтачак.

– Әйтеп тә торасы юк, авыл җирендә эш авыр. Эшлисеңэшлисең, ә акчасы елына бер тапкыр гына керә. Ләкин үз эшебездән тәм табабыз. Әтигә рәхмәт, бу эшне ул башлап җибәрде, без дәвам итәбез. Казан аграр университетында укыганда ук авылга кайтасымны белдем, – ди Риналь.

Татарстан Республикасының Аграр яшьләр берләшмәсе оештырган «Иң яхшы һөнәр иясе» бәйгесе быел бишенче тапкыр үткәрелә. Бәйге 27-28 октябрьдә башланачак, ә анда катнашу өчен гаризаларны ике ай алдан кабул итә башлыйлар. Бәйгедә мал табибы, зоотехник, агроном, авыл хуҗалыгы өлкәсендә эшләүче хисапчы-икътисадчы, механизатор, инженер-механик, сыер савучы һәм бозау караучылар үз көчләрен сынап карый ала. Бәйге теоретик һәм гамәли өлештән тора. Беренчесендә үз белгечлегеңә кагылышлы тест үтәргә кирәк булса, икенчесендә эшеңне гамәлдә күрсәтергә кирәк. Бәйгедә эш тәҗрибәсе бер елдан да кимрәк булмаган һәр яшь белгеч катнаша ала.

– Бу стажировка – һәр катнашучы өчен уникаль тәҗрибә. Германиягә барып кайткан яшьләр күзгә күренеп үзгәрә. Алар авыл хуҗалыгы буенча белемнәрен тагын да тирәнәйтергә тырыша. Үсешкә омтылыш барлыкка килә, үз-үзләренә ышаныч арта, әйләнә-тирәләрен яхшы якка үзгәртү турында уйлана башлыйлар. Бәйге һәркемгә ачык, ләкин үз һөнәре белән янганнар, аның барлык нечкәлекләрен белгән кешеләр генә анда җиңү яулый ала, – диде Татарстан Республикасының Аграр яшьләр берлеге башкарма директоры Илмира Сабирҗанова.

Хәзерге вакытта берлек Голландия, Италия, Белоруссия илләре белән элемтәләрне ныгыта, бәлки якын киләчәктә яшьләр бу илләргә дә белем тупларга сәяхәт итәр.

Бәйгедә катнашу өчен кирәкле документлар

1. Паспорт
2. ИНН
3. СНИЛС
4. Белем алу турындагы таныклык
5. Хезмәт кенәгәсе (ул җитәкче тарафыннан расланган булырга тиеш)
6. Шулай ук «Росмолодежь» сайтына кереп (https://ais.fadm.gov.ru), бәйгедә катнашу өчен гариза калдырырга кирәк.

ИГЕЛЕК КАРТАСЫ

Чыннан да бар бит шундый карта. Һәм, әйтергә кирәк, «Таттелеком» элемтә компаниясен җитәкләүче Лотфулла Нурислам улы Шәфигуллин һәм аның фикердәшләре – кем булуына карамастан (рус, татар, яһүд) үзе кебек риясыз меценатларның хәйрия акчасына башкарылган игелекле гамәлләр хисабына әлеге карта «үз биләмәләрен» елдан-ел «киңәйтә» бара.

Расиха ФӘИЗОВА

Әлеге социаль проектларның кайсысын гына алма, алар һичшиксез тарихка, үткәннәргә барып тоташа һәм аларның бәһасе әйтеп бетергесез. Бу иң тәүдә тарихыбызны барлау, олылау, милли-мәдәни мираска хөрмәт билгесе. Әлеге картаны алып Татарстанны аркылыга-буйга йөреп шуларның кайберләрен генә булса да тамгалап чыгу да аз бу очракта. Чөнки аларның һәркайсы инде үзе бер тарих, үзе бер кыйсса булырлык. Әйтик, әнә Арча районы Хәтнә авылындагы «Изге чишмә» (1); Кырлайда әдәби скульптур парк (2); драматург, җәмәгать эшлеклесе Туфан Миңнуллинның тууына 80 ел тулу уңаеннан аның туган ягы Кама Тамагы районы Олы Мәрәтхуҗа авылында, драматургның исемен мәңгеләштерү ниятеннән, ул туып-үскән йортны тәртипкә китерү (2012 елгы янгыннан соң төп нигезе шактый зыян күргән була), музей-утарын булдыру (3); Казанда «Таттелеком»ның төп бинасы янында элемтәче сугышчыга (прообразы Советлар Союзы Герое Борис Кузнецов) һәйкәл ачу (4); Биектау районында Иске Казан дәүләт тарихи-мәдәни һәм табигать музей-тыюлыгын торгызуда катнашу (музейның административ бинасына ремонт ясау, тарихи корылмалар төзү, территориясен төзекләндерү һ.б.) (5); Әтнә районы Күәм авылы «Кала тау» мемориаль комплексын һәм андагы Әйшә хан каберлеген төзекләндерү (6); Иске Мәңгәр авылында борынгы мөселман каберлеген төзекләндерү (7); татарның мәшһүр мәгърифәтчесе Габденасыйр Курсавиның тууына 240 ел тулу уңаеннан мемориаль комплекс булдыру (8); Ябынчы авылында мәгърифәтче, фәлсәфәче Шиһабетдин Мәрҗани истәлегенә мемориаль комплекс төзү (9); Балык Бистәсе районы Гремячка авылында легендар «Варяг» крейсеры матросы Сидор Александровка мемориаль комплекс төзү (10); Арча районы Иске Кишет авылында Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Гани Сафиуллинның музей-утарын тергезү (11); Симетбаш авылында Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышлап сугыш һәм тыл ветераннары истәлегенә мемориаль комплекс төзү (12); элеккеге Ташлыяр авылы урынында мемориал ачу (13) һ.б. Менә шуларны карап, барлап чыккач, ирексездән, кара инде, ничә еллар кагылгысыз яткан бу җирләргә нигә соң әле элегрәк һичберсенең ни күңеле, ни кулы җитмәгән дип гаҗәпләнәсең хәтта.

ТАШЛЫЯР

«Таттелеком»лылар тотынгач, «Инде япа-ялан басу уртасындагы зиратыннан башка берние калмады авылымның», – дип йөрүчеләрнең дә җаннары тынычлык тапты шикелле. Шулай да җан һаман үзенекен итеп сыкрый бирә: туган авыл, туган нигез дип җирси адәм баласы. Күңеленнән генә булса да, шул беткән авылның урамнарын «урап кайта», өй борынча «кереп», күрше-тирәсенең хәлен белешә. Югалган авылларны барлау ниятеннән, Азнакай районы Ташлыяр авылы (безгә Камал театрының мәшһүр артистлары Нәҗибә Ихсанова һәм Әзһәр Шакировны биргән авыл) урынында узган чара бөтен тирә-як авылларны гына түгел, күрше-тирә районнарны да битараф калдырмады. 30 капкалык кына авыл булса да, авылсыз калуны үз башларыннан кичергән иде шул аларның һәркайсы.

– Ходай Тәгаләгә мең рәхмәтләмен. Авылымның юкка чыгуы күңелемне гомер буе тетрәндерде. Кайткан саен, зиратны күреп өзгәләнә иде җаным. Чөнки ул ташландык хәлдә, камылдан ут кереп янган да иде. Кулына тотып эшләгән кеше ни кичергәндер, әмма минем өстән ниндидер авыр йөк төшкән кебек булды. «Таттелеком»ның генераль директоры Лотфулла Нурислам улына иксез-чиксез рәхмәтем. Әгәр «Шушы урында татар авылы булган» дигән элмә такталарны Россия күләмендә эшли алсак, татар баскан эз беркайда да, беркайчан да югалмас иде, – дигән иде олпат артистыбыз Әзһәр ага, әлеге чарага кайткач.

– Адәм баласы туган җирсез – тамырсыз агач кебек ул. Авыл бер дә истән чыкмый. Бөтенесе дә күз алдында: әти-әнинең бергәләшеп сәкедә намаз укулары да, күрше-тирә авыллардан бәләкәй арбалар тартып килеп, куна-төнә тегермән тартырга йөрүчеләр дә. Без йоклап яткан авыл түгел идек. Дәресләр бетүгә, парталарны артка этәбез дә, авыл буенча җыелган бирнә чаршауларын пәрдә итеп элеп, театр куябыз. Үзем сагыз чәйним, үзем Бибине уйныйм. И-и бөтен халык тәгәрәп көлә торган иде… Тегермән буаларын ничек сагынмыйсың… – ди Нәҗибә апа да, авылы яшьлеген искә алып.

Ә бит «эреләндерү» шаукымына эләгеп, авылсыз-тамырсыз калганнар бихисап…

КЫРЛАЙ

Тукайның 130 еллыгын каршылау җәһәтеннән, Кырлайда Тукайны уллыкка алган Сәгыйтдин Салиховның (Сәгъди абзый) каралты-кураларын төзекләндерү, бәрәңге бакчасы булган урында тулы бер әдәби-скульптур парк (!) булдыру тәкъдиме белән дә нәкъ менә Татарстан Дәүләт Советы депутаты, «Таттелеком» җәмгыятенең генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин чыкты. Бәрәңге бакчасында әнә шундый могҗиза тудырып булыр дип кем уйлаган?! Тәкъдим итеп кенә дә калмый, кем әйтмешли, бүрәнәнең авыр башыннан тотып, җиң сызганып, юбилейга бер ел кала эшкә тотына ул. Инде Сәгъди абзый белән кечкенә Апуш 1893 елда утырткан нарат та шаһит бу эшләргә. Үзе бер әдәби-фәлсәфи архитектура паркына әверелгән ындыр арты буйлап, моннан 100 ел элек Тукай баскан эзләргә басып, су буйларына кадәр төшә бүген туристлар. Нигездә, «Таттелеком» төзүчеләре һәм элемтәчеләре башкарып чыккан бу эш чыннан да соклангыч. Беренче эш итеп, әлбәттә, Сәгъди абзый җирләнгән зиратта мемориаль ясап куела. Бу үзенә күрә олы эш башлар алдыннан хуҗадан хәер-фатиха алу кебегрәк тә була. Арт бакча белән инеш арасында утырган, инде кибеп, җимерелеп, ташландык хәлгә килгән чыгырлы кое да аларның кулы тигәнне генә көткән икән. Коены чистартып, аның су юлын ачып, өр-яңа буралар утыртыла, бер сүз белән әйткәндә, кое икенче сулышын ала. Хәзер «Апуш коесы» дип йөртелә ул. Ә суының тәме турында бирегә килгән юлаучыга кешедән сорыйсы түгел инде. Чүлгә кое казыган – бер саваплы, сазга күпер салган – ике саваплы, юл буена агач утырткан – өч саваплы, диләр бит. Шушы бер тотам җир бөтенесен сыйдырган шуларның. Моңа кадәр тәмам ташландыкка калган ындыр артын хәзер инде танырлык түгел. Койма буйлап дистәләрчә төп агач та утыртылган, кое да казылган, су буена төшәрлек юлы-күпере дә бар. Тукайның «Исемдә калганнар»ы да, аның Шүрәлесе, Былтыры, Су анасы да, Сәгъди абзый да, кечкенә Апуш үзе дә – барысы да шунда…

– Тукайны бер белмәгән кеше дә монда килгәч, аның кемлеген

ГАМӘЛДӘ

аңлап-белеп китәргә тиеш – әлеге паркның максаты шул. Паркны төзекләндерү уе Зиннур Мансуровның «Тукай белән сөйләшү» китабын укыгач туды. Битараф булмаган кешеләр бергә берләштек тә парк-утарны эшләргә булдык. Мин моңа дан-шөһрәт өчен тотынмадым, бары йөрәгенә йон үскән кайбер мәнсезләрне әзрәк кенә булса да уятып булмасмы дип йөрү, – ди үзе дә Кырлайда урта мәктәпне тәмамлаган Лотфулла Шәфигуллин.

Казан буйлап «Тукайлы банерлар» урнаштырып чыгуны да, шигырь бәйрәмнәре уздыруны да аларга йөкләүче булмады ласа, барысына да үзләре тотынды. Өстән төшкән боерыкны көтеп тора торганнардан түгел инде болар. Күңел кушуы буенча эшләү мәслихәтрәк аларга.

– Үзебезнең предприятие кысаларында гына башланган Тукай укулары да бу кадәр резонанс алыр дип уйламадык. Бара торгач, ул үзе бер зур проектка әверелде. 70тән артык мәйданда узып, анда 10 меңнән артык кеше катнашты. Элемтә бүлекчәләребез республиканың һәр районында бар, бу фикерне алар да күтәреп алды. Янәдән Тукай иҗатын барлап чыктык. Ул безнең белән бергә китапханәләргә, мәктәпләргә, мәдәният йортларына үтеп керде. Нинди генә телләрдә яңгырамады Тукай: русча, кытайча, инглизчә... Монда иң мөһиме Тукай мирасына якынаю иде. Ә Тукайны «кулына алган» кеше башка язучыларга да, шагыйрьләргә дә тартылачак, – ди оешманың матбугат хезмәте җитәкчесе шагыйрь Рөстәм Зәкуанов.

ХӘТНӘ

Бу җирләрдә утар корган Перцовны беренче чиратта чишмә җәлеп иткән, диләр. Юкка гына ул авылга Аркадия – Җәннәт почмагы дигән исем бирмәгәннәр. 1797-1801 елларда Россия армиясендә корнет булып хезмәт итеп, Швейцариядә французларга каршы сугышкан Перцов, поручик дәрәҗәсе алуга, отставкага чыга һәм өйләнеп бераз яшәүгә, Казанга күченгән. Җирдә казынырга яратканга-дыр, күрәсең, казнадан җир сатып ала (Казаннан 120 чакрым ераклыкта). Анда чиркәү (1830), тегермән төзи, шәраб җитештерә. 1871 елда авылда мәктәп эшли башлый. Мария һәм Петр Перцовларның сигез ул һәм биш кызлары булу да мәгълүм. Аягында нык торган авыл булган Хәтнә. Үз сырхауханәсе, шифаханәсе, гөрләп торган ике мәктәбе булган авылны башкача ничек атыйсың. Тик 70нче елларда барысы да әкренләп таркалып юкка чыккан. Чиркәүнең XIX гасырның беренче яртысына караган уникаль архитектура корылмасы булараk республиканың архитектура һәйкәле исемлегенә кергән агач өлеше дә нәкъ шул 70нче елларда янып юкка чыга. Кайчандыр гөр килеп торган авыл булгандыр диярлеге дә әллә ни калмаган инде аның – бүген нибары биш йортта 10 кеше яшәп ята анда. Аның каравы, ике гасырлык тарихы булган Хәтнәне бөтен-тирә юньгә таныткан шифалы сулы чишмәсе 2013 елда «Таттелеком» берләшмәсе көче һәм иганәчеләр ярдәме белән төзекләндерелгәннән соң, «Изге чишмә» тирә-юньдәгеләрне үзенең шифалы суы белән тагын да ныграк кинәндерә башлый. Алай гына да түгел, шуннан соң Хәтнә ягына юллары төшүчеләр бермә-бер арта. Юлчыларның күбәюенә тагын бер сәбәп: тарихи Петропавлов чиркәвенә дә реконструкция башлана. Аның янәшәсенә православие динендәгеләр өчен кечкенә генә часовня һәм янәшәдә генә «Изге чишмә»гә килеп ата-бабалары рухына гамәл-гыйбадәт кылучы мөселманнар өчен гыйбадәтханә дә төзелә. Иң кызыгы шунда: авылның янәрыш кичерүен интернеттан күреп, тарихи тамырларын эзләп, Перцовларның нәсел-ыруы да күренгәли башлый авылда. 2014 елда Лотфулла Нурислам улы чакыруы буенча Хәтнәдә Перцовлар нәселенең Мәскәүдә яшәүче бер төркем дәвамчылары – Владимир Перцов, аның әтисе Владимир Валерьевич, оныклары Дуня, Федя, Петя кунак булып китә. Хәер, моңа кадәр дә Перцовларның Хәтнәгә юллары төшми тормаган – 20 еллар элек Сергей Перцов, Казанга ниндидер фәнни конференциягә килгәч, аннан качып китеп, мең бәлалар белән, Хәтнәне күреп киткән булган, Владимир Валерьевичның да беренче генә аяк басуы түгел икән бу җирләргә.

Ә Хәтнә чишмәсенең дәвага ярарлык суы турында риваятьләрне ерактан эзлисе түгел, Перцовлар үзләре дә дәва тапкан бу судан. Әмма шунысы да бар: халык бакча таптап йөрмәсен дип булса кирәк, хуҗалар аны берзаман томалап куйган, диләр. Әмма озак та утми, Перцовлар бөтен гаиләләре белән авырып, урын өстенә кала. Алар моны бары тик халыкның рәнҗеше генә төште дип кабул итә һәм тәүбәгә килеп, чишмәне кабат торгызганнар, диләр. Инде бу кадәрлесен дә белгәч, табигый ташлардан эшләнеп үзе бер комплексны хәтерләткән әлеге табигать һәйкәле юлчыларга яхшылык кылу кебек изге гамәлләр белән беррәттән кеше рәнҗеше, тәүбәгә килү кебек төшенчәләрне дә искәртеп тора кебек.

ИСКЕ КИШЕТ

Советлар Союзы Герое, генерал-лейтенант Гани Сафиуллинның музей-утарын булдыру уе да ничектер, Лотфулла Шәфигуллин үзе дә хәрби кеше булгач, хәрби темага сөйләшкәндә сүз иярә сүз чыгып, үзеннән-үзе килеп чыга. Һәм әйтергә кирәк, музей тулысынча иганәчеләр хисабына эшләнә. Гәрчә коймасыннан башлап баштан-аяк төзәтелеп чыкса да, монда бер генә тиен бюджет акчасы да, «Таттелеком» акчасы да кермәде, диләр. Гани Сафиуллин туган һәм кунакка кайтып йөргән нигез дә, булачак геройны үстергән, соңгы вакытларда келәт булараk файдаланылган 100 еллык корылма да һәр бүрәнәсе кулдан үткәрелеп реставрацияләнә. Мунча торгызыла. Хуҗалардан калган җиһазлар, эш кораллары яңартыла.

– Бик күләмле җитди эш башкарылды, күп көч куелды, эшнең нәтиҗәсе дә күркәм килеп чыкты. 70 ел буена кул тимәгән җирдә менә шундый музей-утар барлыкка килү бәләкәй әйбер түгел. Саратовтан, Казаннан, Ульяновскидан, Кировтан, Самарадан эшмәкәр егетләр кушылды бу эшкә, – ди Лотфулла Шәфигуллин һәм Иске Кишеттән тагын ике-өч булса да офицер чыгуына өметләнә.

Музей дип җан атып йөрүчеләр арасында компаниянең Арча бүлеге җитәкчесе Рөстәм Гомәров белән матбугат идарәсе җитәкчесе Рөстәм Зәкуановның хезмәтен шулай ук югары бәялиләр.

– Чын мәгънәсендә мондый фанатларның булуы бик сөенечле, – ди Лотфулла әфәнде.

Музей чыннан да материалларга бай. Биредә Гани Сафиуллинның шәхси әйберләре (хәрби киемнәр, хәрби бүләкләр, документлар, Татарстан Республикасының Милли музеенда саклана торган шәхси әйберләре турындагы каталог, ул язган хәрби мемуарлар һ.б.) белән беррәттән, стендларда Арча районы биргән башка каһарманнар – Нәкыйп Сафин, Гатаулла Салихов, Валентин Ежковларга да, 1941-1945 елларда Иске Кишеттән сугышка китеп, яу кырында ятып калган сугышчыларга да шактый урын бирелә. Әлеге күләмле эшләрнең Бөек Җиңүнең 70 еллыгына багышланып, «Безнең кадерле ветеран» дип аталган социаль-гуманитар проект кысаларында эшләнүе дә олы мәгънәгә ия. Нәтиҗәдә беркем дә читтә калмый.

«Безнең хәтер еллар агышына караганда көчлерәк булырга тиеш!» – музей-утар һәм монумент ачылу тантанасында яңгыраган чыгышларның асылында әнә шул фикер ята иде. «Таттелеком» акционерлык җәмгыяте генераль директоры Лотфулла Шәфигуллин кебек бик күп кенә асыл затларыбыз нәкъ менә шул фикерне күз уңында тотып эш итәдер дә. Юкса борынгы татар байларыннан ук килгән иганәчелек, хәйриячелек кебек асыл гамәлләрне дәвам итүчеләр сафында булыр идеме икән алар? Йөзләрчә авыл мәктәпләрендә булдырылган күпсанлы спорт мәйданчыклары, төзекләндерелгән дистәләгән чишмәләр, җир йөзендә үзеннән соң каберлекләрен дә ятим калдырып эзсез югалган авылларның ташландык зиратларын карап тәртипкә китерү һәм башка бик күп изге гамәлләрне барлаганда без нәкъ менә аларның исемнәрен беренчеләрдән булып юкка гына атамыйбыз инде.

Ике икең дүрт булмаса?

Үтеп барышлый

Равил САБЫР

Бер төш кереп интектерде берничә ел. Имеш, Казан университетының 2нче корпусының 13нче катында (без укыганда, журфак шунда урнашкан иде) аптырап йөрим икән. Юк, аптырап кына түгел, бөтенләй коелып төшкәнмен икән дим. Чөнки сабакташларым диплом алганнар, алар барысы да бәхетле, бер-берсен котлыйлар, кочаклашалар, үбешәләр, ә минем әле хәтта IV курс өчен имтиханнар тапшырылмаган. Шыбыр тиргә батып уяна торган идем! Төш кенә икәнен аңлагач, шундый җиңел, рәхәт булып китә иде.

УТЫР, «БЕРЛЕ»!

Нигәдер мәктәптәге имтиханнарның берсе дә истә түгел. Университетка кергәндә тапшырганнары да әллә ни хәтердә калмаган. Дөрес, IV курста укыганда, апрель өмәсендә архивта эшләп алган идек бераз. Шул чакта мин үземнең укырга кергәндә тарихтан биргән имтихан кәгазьләрен тапкан идем. Петр I турында билет эләккән булган икән. Үз язганнарымны укып, үзем шаккаткан идем. Ул белемнәрнең берсе дә башта калмаган иде инде…

Хәер, мәктәптә дә бер кызыклы хәл булган икән, тик имтихан тапшырганда түгел анысы. Җиденче сыйныфта укыганда, урыс әдәбиятыннан Есенинны үткән идек дәрестә, укытучы апа аның бер шигырен ятлап килергә кушты. Теләсә кайсысын, үзең сайлап алып. Ә миңа кызык ясарга гына булсын! Аңа кадәр үк Есенинның шигырьләрен бик күп укыган идем инде, күбесен яттан белә идем, бигрәк тә «Москва кабацкая» дигән циклны. Киттем мин мәктәп китапханәсенә, үземә кирәкле шигырь кергән китапны эзләп таптым.

Гөнаһ шомлыгы, икенче дәрестә иң беренче мине такта янына чыгарып бастырды апа. Булдыра алганча сәнгатьле итеп кычкырып укый башладым…

Сыпь, гармоника! Скука… Скука…
Гармонист пальцы льет волной.
Пей со мною, паршивая сука.
Пей со мной.

– Утыр, «берле»! – ди укытучы апа.

– Ни өчен?! – мин әйтәм.

– Утыр, «берле»!

Дөрес, икенче дәрестә өй эшен тагын сорап, мин «бишле»лек җавап биргәч, апа «берле»не «дүртле»гә төзәткән иде…

БАКА КОЙРЫГЫ ТУРЫНДА

Есенин иҗатын яхшы белүем университетта укыганда шактый булышкан иде. Бака койрыгы турындагы мәзәктәге кебегрәк булды инде ул. Белмәгәннәргә мәзәген дә сөйлим инде. Бер студент имтиханга әзерләнергә җитешмәгән, койрык төзелешен генә укыган икән бу. Билетта беренче сорау ат турында ди. «Ат – йорт хайваны, аның койрыгы бар», – дигән дә бу, сөйләп киткән рәхәтләнеп койрык турында. Икенче сорау төлке турында икән. «Төлке – кыргый җәнлек, аның да койрыгы бар», – дигән студент һәм тагын койрык төзелешен сөйләргә тотынган. Профессор: «Менә, дустым, бака – койрыксызлар семьялыгына керүче җир-су хайваны, шуңа күрә аның койрыгы юк. Аның турында сөйләп карагыз әле», – дигән. «Әйе, чыннан да баканың койрыгы юк, – дигән студент. – Дөрес, бала чакта ул бит чукмарбаш була, ә аның койрыгы бар. Койрыкның төзелеше…» – дип, студент тагын үз белгәнен сөйләп киткән.

Мин дә урыс әдәбиятыннан бер-бер артлы өч имтиханны Есенин турында сөйләп, «бишле»лек тапшырган идем. Гуманитар фәннәрне шуның өчен дә яратам мин. Чөнки, әйтик, математикадан: «Ике икең ничә?» – дип сорасалар, аның дүрт икәнен белү генә җитми, әле шуны исбатлап та күрсәтергә кирәк. Ә әдәбиятта иң мөһиме, телең тик тормасын, белгәннәреңне сөйлә дә сөйлә.

Керәм, мин сиңа әйтим, урыс әдәбиятыннан имтиханга, нинди генә сорау эләксә дә, тегеләй итеп, болай боргалап теге койрык турында сөйләгән студент шикелле каерып алып чыгам сөйләшүне Есенинга, ә аның турында мин сәгатьләр буе сөйли алам. Өченче имтиханда да Сергей Александрович «сыртына утырып чыккач», әйтә миңа профессор: «Дустым, сез моны өченче мәртәбә сөйлисез инде… Тик шундый мавыктыргыч итеп сөйлисез, «бишле» куймыйча булмас», – ди.

«АЛТЫЛЫ»?

Тагын бер «бишле» алганым мәңгегә истә калды, анысы чит ил әдәбиятыннан имтихан тотканда булды. IV курс бу, мин инде ул чакта «Татарстан яшьләре»ндә ду китереп эшләп ята идем. Эшне дә җиренә җиткереп башкарасы килә, укырга вакыт әллә ни калмый иде. 25-30 китап укып җитешергә кирәк һәр семестрда. Каян барысын да укып бетерәсең инде аларның?

Җыеп әйткәндә, чит ил әдәбиятыннан имтихан тапшырырга бөтенләй дә әзер түгел идем мин. Алай да киттем. Килсәм, аудитория ишеге төбендә безнең группа кызлары җыелган, сырып алдылар болар мине. «Син ничәнче булып керәсең?» – диләр. Кызларның үзара шундый бер ырым-юраулары барлыкка килгән икән, имеш, имтихан бирергә миннән соң керсәләр, яхшы билге алачаклар.

– Кызлар, бүген күп дигәндә «икеле» куялар миңа, укытучының иң ачулы чагына гына эләгәсез, – дим.

Шулвакыт укытучы биш кешегә аудиториягә керергә кушты. Барысы да ничектер икеләнеп тора иде, мин беренче булып кердем дә киттем. Миңа нәрсә? «Икеле»дән башка нәрсә югалтасым юк барыбер. Минем арттан тагын дүрт кеше кереп утырды. «Укыган китапларыгызның исемлеген языгыз», – ди укытучы. Минем зачеткадан башка бер нием дә юк. Кемнәндер бер кәгазь бите сорап алдым, икенче берсе кызыл паста биреп торды, чөнки беркемдә дә артык ручка да, каләм дә юк иде. Мин шул кызыл паста белән шакмаклы дәфтәр битенең иң өстенә үзем укыган бердәнбер китапны язып куйдым: Джон Стейнбек. «Гроздья гнева».

Янымда сабакташым утыра иде.

– Ярар, Рома, – мин әйтәм, – Аллага тапшырып киттем мин.

– Тукта ашыкма инде, списогыңны күчереп алырга бир әле, – дип пышылдады Рома.

– Мә, – дип, кәгаземне суздым тегеңә.

– Ычкындыңмы әллә син?! – диде Рома, имән бармагын чигәсендә бөтергәләп. – 25 китап укымасаң, имтиханга кертми дә ул!

– Мин кайтып киттем алайса. Берне генә укыдым ич, – дим.

– Тик кенә утыр! Берәү дә 25не укымаган инде. Менә хәзер һәркем үзе укыган китапларны язып чыга, аннары кәгазьләрне алмашабыз да, шулай итеп гомуми список төзибез. Биш кешенекен бергә кушкач, 25кә туларга тиеш, – дип аңлатты планны Рома.

Калган 24 китапның исемнәрен язарга миңа Рома үзенең зәңгәр пасталы ручкасын биреп торды.

– Йә, кайсыгыз иң батыр? Беренче булып имтихан тапшырган кешегә бер балл өстәп куям, – диде укытучы.

– Мин! – дип, кулны күтәрдем шундук. Бер балл өстәп куелгач, «өчле» кесәдә дигән сүз бит инде бу!

Килеп утырдым укытучы каршына, исемлегемне тапшырдым.

– Стейнбекны сөйләп карагыз әле, – ди бу.

И киттем сөйләп, мин сиңа әйтим! Автор белән кайвакыт бәхәсләшеп тә алам: «Бу проблемага фәлән язучының карашы башка төрлерәк булган, ул шулай-шулай дип язган фәлән әсәрендә», – дип сиптерәм генә, малай!

– Ярар җитеп торсын, – дип туктатты бу мине берзаман. – Мин батырлык өчен бер балл өстәп куям дип вәгъдә иткән идем, шуңа күрә сезгә «алтылы», – диде дә зачеткага «отлично» дип язып куйды.

Коридорга чыккач, кызлар: «Ничәле?», «Ничәле?» – диешәләр. Алтылы, мин әйтәм. «Ничек «алтылы»?! Өч «икеле» куйдымыни?!» – дип сорады берсе. Юк, мин әйтәм, «бишле» һәм батырлык өчен өстәмә тагын бер балл!

КЕШЕ КҮҢЕЛЕН КҮРӘМ ДИП…

Читтән караганда бәлки чыннан да шулай тоелгандыр ул, тик чынлыкта «бишле»лек белеп тә, «өчле» алган чаклар да булды. Шулай берсендә урыс әдәбиятыннан имтихан бирәбез. Минем белән янәшә утырган сабакташымның иреннәре калтырый, күзләре дымланган – кыскасы, берни белми бу. Билетын карасам, беренче сорау – А.П. Сумароковның «Дмитрий Самозванец» әсәре. «Өчле» булса да алсын инде, дип, өстән-өстән генә җавап язып бирдем мин моңа. Бу, укытучыга барып, мин язганны абына-сөртенә, куркыныч акцент белән укып чыкты да, «дүртле» алып, авызын ерып чыгып та китте.

Аның артыннан мине чакырткан укытучы. Билетта беренче сорау «XVIII гасыр урыс әдәбиятына күзәтү» иде. Минем сөйләмәгән нәрсәм калмады: Ломоносовның одалары, Фонвизинның «Недоросль» һәм башка әсәрләре, Державин, Радищев һ.б. «Ярар беренче сорауны «бишле»лек беләсез», – диде укытучы. Икенче сорау белән авыррак тора иде хәлләр. Михаил Чулковның «Пригожая повариха» дигән романы турында сөйләргә кирәк иде, ә мин аны укырга җитешмәдем. «Ә нәрсәләр укыдыгыз?» – дип сорады укытучы. Мин өч-дүрт китап исемен атадым да төртелеп калдым. Андый чакта башы да юньләп эшләми бит аның, заразы! «Бик аз укыгансыз», – диде дә бу, «өчле» чәпеп куйды.

Башкаларга яхшылык эшлим дип, тагын бер мәртәбә яндым әле мин. Диннәр тарихыннан зачет биргәндә, бер сабакташ кыз билетын күрсәтте: «Бу сорауга җавапны белмисеңме?» Белгәнемне язып бирдем кыскача. Аннары тагын берсе сорады, аннары өченчесе. Укытучы моны күреп, сизеп утырган икән. Иң кызыгы шунда, ул кызларны тыңлады да аларга зачет куеп кайтарып җибәрде, ә мине иң ахырга калдырды. Әлбәттә инде, ул бу фәнне миңа караганда 100 мәртәбә яхшырак белә, шуңа күрә өстәмә сораулар бирә-бирә «батырды» бу мине. Икенче көнне «зачет куймады» дигәч, сабакташларым озак кына ышанмыйча тордылар һәм бик аптырадылар.

Өч-дүрт көн үткәч, тагын килдем зачетка, тагын куймады бу. Һәм тагын, тагын, тагын! Инде зачетларны тапшырып бетереп, имтиханнарга күчәр вакыт җитте, ә минем диннәр тарихы «эленеп тора». Ярый әле деканыбыз Флорид Әгъзәмов бик игелекле кеше иде, бер зачет бирелмәгән булса да, имтиханнар тапшырырга махсус рөхсәт кәгазе язып бирде. Тора-бара бу вазгыять бер анекдотка әйләнде. Берәр имтихан тапшыра башласак, мине күрү белән, дежур сорау яңгырый: «Диннәрдән зачет алдыңмы соң инде, Равил?» Юк әле, дигәч, барысы да рәхәтләнеп шырык-шырык көлә.

14 (!!!) мәртәбә бардым шул зачетны тапшырырга, ышанасызмы? 14!!! Талашмадым, тавышланмадым, бары тик укытучы биргән сорауларга белгәннәремне тыныч кына сөйләп бирә торган идем. Ахыр чиктә: «Каты башлы малай булып чыктың син», – дип куйды зачетны тәки.

АРТЫК «ДҮРТЛЕ»

Оят булса да тагын бер очрак турында сөйлим инде. Берсендә Бауман урамыннан барам, карасам – курсташлар каршыга килә. Безнең 1302 группасы ике төркемгә бүленгән иде: татар һәм урыслар. Миңа әнә шул урыс подгруппасында укый торган иптәшләр очрады. «Кая барасыз?» – минәйтәм. Менә фәлән кешегә имтиханны тапшыра алмаган идек, хәзер аның өенә барабыз, диләр. «Минеке дә тапшырылмаган бит ул, мин дә сезнең белән барам», – дим.

Киттек без җыелышып профессорның өенә.

Имтихан тапшыруның тәртибе мондый: квартирага берүзең генә керәсең дә профессордан ике китабын сатып аласың. Синең акчаны өстәл тартмасына шудырып төшерә дә бу, зачеткага «дүртле» куя.

Икенче көнне үзебезнең татар подгруппасы кызлары янына килеп бастым авызымны ерып.

– Хәлләр шәп! – мин әйтәм. – Менә кичә генә әле «дүртле» алдым.

– «Дүртле»? Нинди фәннән?

– Шундый-шундый фәннән, – димен.

– Без ул фәнне укымадык бит, урыс подгруппасы гына йөрде ул лекцияләргә, – диделәр дә кызлар, тәгәри-тәгәри диярлек миннән көләргә тотындылар.

Мин, башны иеп, декан янына киттем. Шулай-шулай, мин әйтәм, Флорид абый, ялгыш артык «дүртле» алганмын. «Куйганнар икән, торсын, ашарга сорамый бит», – диде.

КАЛГАННАРГА – «ӨЧЛЕ»

Дәүләт имтиханын тапшырганда да Флорид абыйның олы йөрәкле булуы коткарды мине. Бик уңышсыз билет эләкте. Артык дулкынланудан һәм борчылудан, ахрысы, үтереп баш авырта башлады. Бик начар җавап бирдем мин, кыскасы.

Имтиханны Флорид абый белән Рафаэль Мостафин икәүләп алалар иде. Рафаэль абыйга минем җаваплар бер дә ошамады. Шунда Флорид абый мине мактарга тотынды, берничә мәкаләмне искә төшерде, аларның бик үзенчәлекле булулары турында әйтте. «Барыннан да бигрәк миңа Равил Фәйзуллиннан 50 яшьлеге уңаеннан алынган интервьюсы ошады! Шагыйрь юбилеен йөзеп каршы алырга ниятләгән. Адашы белән сөйләшер өчен, Равил Компрессорный күпереннән Ленин дамбасына кадәр аның белән бергә йөзеп барган!» – диде Флорид абый, матур итеп елмаеп.

Рафаэль абый исә һаман да шулай кырык карап, коридорда бераз көтеп торырга кушты. Кырыктан артык студент идек без курста, дәүләт имтиханыннан берәү «бишле» алды, тагын ике «дүртле» бар иде, калганнарныкы – «өчле». Шул ике «дүртле»нең берсе минеке иде…

Иң кызыгы шунда, эшкә урнашканда: «Нинди билгеләргә укыдың?» – дип берәү дә кызыксынмады, дипломның номерын гына язып алдылар.

«Имплант ул күлмәк түгел»

Ничек итеп яшь һәм матур булып калырга? Әлеге сорау бигрәк тә гүзәл затларны борчый. Матурлык индустриясе дә тик тормый, бигрәк тә пластик хирургия елдан-ел популярлаша. Пластик хирург Антонио Нтире белән дә без эстетик пластика турында сөйләштек.

Дилбәр ГАРИФУЛЛИНА

– Антонио Марселович, сезнең пациентлар кемнәр алар?

– Элек пластик операцияне бай кешеләр, шоу-бизнес йолдызлары гына ясата дигән фикер яшәп килә иде һәм нишләптер аны күкрәк зурайту белән генә бәйләп карадылар. Пластик хирургия аңа гына кайтып калмый, ул күптөрле һәм бер урында гына да тормый. Безнең пациентлар – гап-гади кешеләр. Алар арасында яшь кешеләр дә, өлкәнрәкләр дә, шул исәптән ирләр дә бар.

– Иң популяр операцияләр, мөгаен, күкрәк зурайту һәм борын формасын үзгәртүдер...

– Әйе, мондый мөрәҗәгать белән килүче пациентларыбыз шактый. Яшьрәкләр күбесенчә борын формасын үзгәртүне сорый, урта яшьләрдәгеләр күкрәк коррекциясенә килә, ә 50 яшьтән узганнар исә күбесенчә салынып торган күз кабагыннан котылырга, битләрен яшәртү процедураларын үтә.

– Пациентлар канәгать калмаган очраклар буламы?

– Минем пациентларның дәгъвалар белән килгәне юк. Әмма андый очраклар булгалый, бу иң элек пациентның нәрсәгә өмет итүеннән дә тора. Операция алдыннан алар консультациягә килә. Һәр моментны җентекләп сөйләшәбез, аннары операцияне планлаштыруның заманча алымнары да бик күп. Кайвакыт бер операция белән генә чикләнеп булмаячагын да кисәтәбез.

– Күкрәкне зурайтканнан соң имплантны алырга яки кечкенәрәк размердагысын куярга сораганнары бармы һәм гомумән бу мөмкинме?

– Хирургиядә мөмкин булмаган әйбер юк. Ике атна элек бер пациент килеп, куйдырган имплантын алдырырга сорады. Мин ашыкканмын, моңа әзер түгелмен икән, диде. Аңа имплантны башка бер клиникада куйган булганнар, нишләптер хирургы кабат кабул итәргә теләмәгән. Ярдәм сорап безгә килде, имплантын алдык, пациентның сәламәтлегенә бәйле бернинди проблемалар да юк. Шуны әйтәсем килә: чит кеше эшләгән эшне төзәтү үзең ясаган операциядән күпкә катлаулырак. Кызганыч, андый очраклар да булгалый.

– Күкрәкләренә артык зур размердагы имплант куйдырырга теләүчеләр булдымы?

– Без, әлбәттә, пациентның теләкләрен ишетәбез, әмма шул ук вакытта табиб беренче чиратта аның нәтиҗәсе турында да уйлый. Зур күкрәк аның анатомиясенә туры килмәскә, әйтик, күкрәк читлеге тар булырга мөмкин. Ул бит җәйсыз да, аны «күтәреп йөрүче» умыртка баганасында үзгәрешләр барлыкка килә. Имплант бит ул күлмәк түгел, аны гел алыштырып булмый. Зур күкрәкләр кайбер кешеләр өчен эстетик яктан да матур булмаска мөмкин. Имплантларның, формалары һәм размерларына карап, өч йөздән артык төре бар, бәлки, күбрәктер дә. Алар арасыннан идеаль форма һәм зурлыктагысын табу авыр түгел. Без имплантларны рәсми дистрибьюторлар аша ышанычлы җитештерүчеләрдән генә алабыз.

– Имплант гомерлеккә куеламы?

– Әгәр дә аны организм «кабул итсә» («кабул итмәү» бик сирәк очракта гына була), пациент формасы һәм размерыннан зарланмаса, 7-15 ел да тора ала. Әгәр дә инде тагын да зуррак размер кирәк дисәләр, заманчарак имплантка алыштырасылары килсә, имплант торган урында ниндидер ялкынсыну булса, ниндидер җәрәхәт аркасында формасы үзгәрсә, алыштырабыз.

– Аның күкрәк белән имезүгә берәр тәэсире бармы?

– Имплант куйдырган хатын-кызларга борчылырга кирәкми, аның бернинди дә тәэсире юк. Ә менә ул артык зур булса, уңайсызлыклар тудырырга, сөт аз килергә мөмкин.

– Пациентларыгызны, сезгә эстетик операция кирәк түгел, дип үгетләгәнегез бармы?

– Һәр атна диярлек андый очраклар була. Ул сәламәтлекләре белән дә һәм хирургтан мөмкин булмаганны таләп итүләре белән дә бәйле.

– Антонио Марселович, ничек уйлыйсыз, соңгы елларда матурлык эталонында үзгәрешләр булдымы?

– Моннан унбиш еллар элек зур күкрәкләр модада иде, хәзер исә хатын-кызлар моңа сак карый, артык зур размерларга кызыкмыйлар. Ирен күпертү модасы тиз чыкты, алар табигый зурлыкта булырга тиеш. Үз эшенә җаваплы караган хирург битнең өчтән бер өлешен алып торган иреннәр эшләргә алынмый да. Намуссыз табиб пациентка аның нәтиҗәсе турында аңлатып та тормаска мөмкин, сорадылар икән, эшлим, ди ул.

– Күпләр, пластик операция ярдәмендә, тормышыңны үзгәртеп була, дигән фикердә тора. Сез моңа ничегрәк җавап бирер идегез?

– Безгә мөрәҗәгать итүчеләрнең күбесе борын формасыннан канәгать түгел. Операциядән соң алар үзендә ниндидер ышаныч тоя башлыйлар, комплекслары югала. Тормышлары үзгәрми, ә үзләре үзгәрә. Шуның белән тормышка карашлары үзгәрә.

– Без гел хатын-кыз пациентлар турында гына сөйләшәбез, ир-атлар киләме соң сезгә?

– Килә, әмма бик сирәк. Алар шулай ук борын һәм колак формасын үзгәртүне сорыйлар. Пациентларның 5-10 проценты гына – ирләр. Шунысын да әйтергә кирәк, пластик хирургка мөрәҗәгать итүчеләрнең саны елдан-ел артып тора. Бездә һәр көнне бер-ике операция ясала. Мин моны аның куркынычсыз булуына инануларыннан һәм аның өчен матди мөмкинлекләре булудан килә дип уйлыйм.

– Сер булмаса, пластик операция күпме тора?

– 150 меңнән башлап 200 мең сумга кадәр.

– Иң кыйммәтлесе кайсы санала?

– Күкрәк коррекциясе.

– Сезнең өчен иң катлаулы операция?

– Пластик хирургиядә иң катлаулысы битне тарттыру, ринопластика, ягъни борын формасын үзгәртү һәм маммопластиканың кайбер төре. Миннән еш кына, операциянең кайсы төрен ясарга яратасыз, дип сорыйлар. Барысын да яратам. Минем өчен иң мөһиме – пациентның операциядән канәгать калуы.

– Күптән түгел генә телевизордан Чечняда пластик операциядән соң сәламәтлегенә зыян килгән бер кыз турында сөйләделәр. Волгоградта да шундый ук хәл булган, диделәр. Пластик операцияне өй шартларында ясаучылар турында да ишетеп торабыз. Клиника һәм хирургны сайлаганда нәрсәләргә игътибар итәргә кушасыз?

– Андый коллегалар өчен безгә дә кызарырга туры килә. Алар, акчага алданып, кеше язмышы белән уйныйлар. Пациентлар да нинди адымга баруларын белергә тиеш. Пластик хирургия ул маникюр ясату түгел, шуңа да реанимация бүлеге дә, анестезиологы да булган лицензияле клиникага мөрәҗәгать итәргә кирәк. Табибка килгәндә, аның моңа сертификаты булу зарур. 20 мең сумга арзанрак булган операциягә кызыгырга кирәкми.

– Сез үзегезгә пластик операция ясатыр идегезме?

– Әлегә андый ихтыяҗ күрмим.

– Матурлык эталоны дип кемне әйтә аласыз?

– Хатын-кызлардан – киноактриса Моника Беллуччи, ир-атлардан – җырчы Муслим Магомаев, актер Вячеслав Тихонов.

– Эстетик пластика турында уйлап, табибка килергә курыккан яки шикләнгән кешегә ниләр киңәш итәсез?

– Консультациягә килергә. Интернеттан алынган мәгълүматларга гына таянырга кирәкми дип уйлыйм. Консультация барышында ул үзен кызыксындырган бөтен сорауларны да бирә ала. Табиб белән аралашканнан соң, үзе тәгаен бер фикергә киләчәк. Консультация өчен бер хирургка гына түгел, тагын берничә табибка барырга кирәк. Ашыгыч хирургия түгел, җентекләп чагыштырырга, уйларга вакыт бар.

ӘЗ-МӘЗ ТАРИХ

Күкрәкне зурайту буенча иң тәүге операция 1895 елда немец хирургы Винценс Черни тарафыннан ясалган. Яман шеш авыруы сәбәпле күкрәге алынган хатын-кызга имплант буларак аның аркасындагы зарарсыз шешне (аны липома, жировик дип тә әйтәләр) кулланган. 70 ел буена табиблар имплант сыйфатында парафин, пыяла шарчыклар да, балавыз да, хәтта фил сөяген дә куеп караган. 1960 елда Фрэнк Джироу дигән хирург силикон имплант уйлап тапкан. Аны беренче тапкыр эттә кулланып караганнар.

БУ – КЫЗЫК!

✓ Америка Кушма Штатлары – пластик операцияләр, бигрәк тә маммопластика буенча лидер. 2015 елда анда күкрәкне зурайту буенча 309 985 операция ясалган. Бу аңлашыла да – Голливуд, дөнья йолдызлары, Барби... Хатын-кызларга стимул җитәрлек.

✓ Бразилия – 166 430 операция.

✓ Мексика – 61 613 операция. Бирегә, бәясе арзанрак булганга, Америкадан да килеп ясаталар.

✓ Германия – 53 376 операция.

✓ Көньяк Корея – 50 553 операция.

✓ Колумбия – 46 702 операция. Аның 20 процентын Испания, АКШ һәм Канададан килгән пациентлар алып тора.

✓ Франция – 41 924 операция.

✓ Һиндстан – 29 606 операция. Болливуд, әлбәттә, Голливуд түгел, әмма анда да матурлык стандартлары бар.

✓ Италия – 23 400 операция.

(pressa.tv)

СЕЛФИ ҺӘМ ПЛАСТИКА

Иң популяр сүз, мөгаен, селфидыр. 2013 елда ук Оксфорд сүзлеген төзүчеләр аны «ел сүзе» дип атаган иде. Көндәлек тормышыбызның бер элементы булган әлеге дә баягы селфи хатын-кызларны пластик хирургка мөрәҗәгать итәргә этәрә икән. Алар косметик процедурага фәкать селфи матур чыксын өчен генә барырга риза булган.

КУНАК БҮЛМӘСЕ

Зөфәр Хәйретдинов:

«Җыр – бакча җимеше түгел, акча җимеше»

Шәхсән үземне әлеге тема күптәннән кызыксындыра иде. Шагыйрь һәм композиторларның, драматургларның шәхси милке булып саналган әсәрләрнең хокуклары ничек яклана? Авторларга гонорар түләү мәсьәләсе ничек хәл ителә? Һәм ул лаеклымы? Хәер, Россия авторлар җәмгыятенең (РАО) Татарстан буенча филиалы директоры, Татарстанның халык артисты Зөфәр Хәйретдинов белән сөйләшер өчен сәбәпләр дә шактый җыелган иде. Соңгы вакытларда җырчылар һәм авторлар арасында килеп чыккан низаглар турында да еш ишетелә башлады, аннан соң, мәгълүм булганча, узган ел ахырында гына Россия авторлар хокуклары җәмгыятенең элеккеге җитәкчесе кулга алынганнан соң, яңа директор итеп Максим Дмитриев билгеләнде. Шуңа күрә тагын бер максатым – дилбегә башка кеше кулына тоттырылгач, җәмгыять эшчәнлегендәге үзгәрешләр турында да белешү иде.

Зөһрә САДЫЙКОВА

– Зөфәр әфәнде, иң элек Россия авторлар җәмгыятенең оешу тарихына тукталасы килә.

– Җәмгыятьнең тарихы бик тирәнгә китә аның. Беренче тапкыр ул 130 еллар элек оешкан. Аннан соң акрынлап формалары үзгәрә-үзгәрә килеп (Авторлык хокуклары буенча бөтенсоюз агентлыгы, Интеллектуаль милекнең Россия агентлыгы), 1993 елда РАО булып атала башлады. Гади генә итеп әйткәндә, аның вазифасы – Россия авторларының милки хокукы белән идарә итү. Драматургларның хокуклары белән идарә итү җиңелрәк, чөнки театрлар да билгеле, драматурглар да бармак белән санарлык. Аларның хокукларын Татарстанның интеллектуаль милек агентлыгы яклый. Ә шагыйрь һәм композиторларның әсәрләре бик күп һәм бу тармакта эш алып бару аеруча катлаулы.

– Җәмгыятьнең әлеге эшчәнлеге ничек, нинди тәртиптә оештырылган?

– Әсәрләре яңгырый башлагач, автор җәмгыять белән килешү төзи. Ягъни оешмага үз исеменнән эш алып барыр өчен рөхсәт бирә. Шуннан соң җәмгыять, шушы килешү нигезендә, кулланучы (башкаручы) белән кабат килешү төзи. Монысы теге яки бу әсәрне кулланырга рөхсәт бирә. Кеше нинди генә өлкәдә эшләсә дә, нәрсәнең яхшы, нәрсәнең яман икәнен белергә тиеш. Башкаручы белән дә шул ук хәл. Ягъни сәхнәгә чыкканчы, ул безнең белән килешү төзергә тиеш. Шуннан соң гына аның сәхнәгә чыгып җырларга хокукы була. Ә бездә, кызганычка, беләме-белмиме, сәхнәгә чыга, әмма чыкканчы ук законны боза. Бик сирәк җырчылар гына белә моны, ә бәлки белеп тә үтәмиләрдер. Кызганычка, безгә күп очракта концерттан соң гына килешү төзергә туры килә. Һәм кайвакыт аны төзергә теләмәүчеләр белән башка төрле сөйләшергә мәҗбүрбез. Закон бозучыларга 10 меңнән 5 миллион сумга кадәр штраф каралган. Ә килешү булган очракта, концерттан җыелган акчаның 5 проценты РАО аркылы авторларга җиткерелә. Акча шактый күп килсә, хезмәт хакы авторларга ай саен күчерелә, әгәр аз икән, җыелган сумма 500 сумнан арткач кына шагыйрь яки композиторның кесәсенә керә.

– Автор үзе дә турыдан-туры башкаручы-кулланучы белән килешү төзи ала бит.

– Әлбәттә, бу очракта җәмгыятьнең кирәге дә юк. Автор үзенең иҗат җимешен кемгә дә булса тәкъдим иткәннән соң, бәясе, авторлык хокукларының вакыты, күләме (өлешчәме, бөтенләйгәме) буенча уртак фикергә килеп, ике арада килешү төзелә. Килешүдә башка бик күп төрле мәсьәләләр күрсәтелергә мөмкин. Чикләнгән (өлешчә) мөмкинлекләр дигәндә, авторлык хокуклары билгеле бер вакытка гына бирелә. Ә хокуклар бөтенләйгә бирелгәндә, авторның хокукы бары тик исемгә генә кала.

– Мондый килешүләр бик аздыр алайса?

– Аз түгел, байтак. Авторларның күбесе җәмгыятькә ышанмыйча, әллә ул безнең өчен акча җыя, әллә юк, дип уйлап, җырны җырчыга сатып җибәрә. Һәм шуның белән гонорар алу хокукын да бетерә.

– Димәк, авторларга түләнә торган гонорар да җырның популярлыгына бәйле дип аңлыйм.

– Әйе. Әгәр җыр бик популярлашып китсә, гонорар да бик яхшы чыга. Мәсәлән, үземне мисал итеп алсак, 80нче еллар ахырында минем биш-алты җырым бар иде. Аларның икесе – «Су буенда учак яна» һәм «Кайда син, гармун?» бик популяр булды. Менә шушы ике җыр өчен мин аена 10-12 сум акча ала идем. Ул елларда бик яхшы бәя иде бу. СССР таркалгач, РАОның милли авторларга карата мөнәсәбәте начарайды. Йөзләгән җырым була торып та, гонорар юк дәрәҗәсендә иде. Сәбәпләрен төгәл генә әйтә алмыйм – әллә Мәскәүдә утыручы түрәләр хилафлык китерә, әллә җырчылар авторларга түләргә теләми. Мин монда 15 елдан артык эшлим. Җәмгыятькә акчага кызыгып, түрә булыр өчен килмәдем, чөнки мондагы айлык хезмәт хакын мин бер концертта эшләп алыр идем. Инде шактый җырларым язылган, кем әйтмешли, елганың бу як ярын беләм, икенчесен дә күреп карыйсым килде. Мөрәҗәгать иткән бөтен җырчыга язарга тырышам. Салават, Хәния, Ришат Төхвәтуллин һәм Филүс Каһиров кебек җырчыларга җырларымны сатып биргәнем юк. Ә инде таныла гына башлаган җырчыларга, җыр әрәм булмасын дип, сатып бирәм. Җырның бәясен чыгарырга кирәк бит. Авторның иҗат җимешен сатып алдың да кесәгә тыгып куйдың гына түгел. Сыер файда китерсен өчен, аны саварга кирәк. Иҗат әсәре белән дә шулай ук, ягъни ул авторга һәм башкаручыга популярлык һәм акча китерергә тиеш. Җыр – бакча җимеше түгел, акча җимеше. Аның да үз бәясе булырга тиеш. Шуңа күрә әлеге эшкә мине авторларның акчасы кая бара, бу система ничек эшли, безгә дөрес бәя бирәләрме, юкмы икән, дигән кызыксыну алып килде. Россия авторлар җәмгыятен оештырып, эшне җайга салганчы шактый эш эшләргә туры килде. Аңа кадәр Татарстанның интеллектуаль милек агентлыгы, Татарстан авторлары җәмгыяте, РОЗА бар иде. Нәтиҗәдә хаос барлыкка килде. Шушыны бетерү максатыннан, 2008 елда закон кабул ителде. Аның нигезендә бер генә җәмгыятькә, ягъни Россия авторлар җәмгыятенә аккредитация бирелде. Һәм без хәзер бөтен Россия авторлары исеменнән эш йөртәбез. Ягъни Татарстанда татарлар, руслар, чит ил җырчылары катнашында нинди чара уза, барысын да контрольдә тотып, гонорар җыябыз һәм аны Мәскәүгә җибәрәбез.

– Бүгенге көндә иң популяр авторлар, дигән вакытта, кемнәрне күз алдында тотасыз?

– Оскар Усманов, Фирзәр Мортазин, Альфред Якшимбетов һәм Зифа Нагаева дияр идем.

– Димәк, билгеле бер чарада башкарылган җыр өчен башкаручыдан бигрәк, чараны оештыручы җаваплы? Аларның барысы артыннан да күз-колак булып бетерү мөмкин хәл түгелдер кебек.

– Мөмкин. Әммә керемнең 5 процентын бик сирәк очракта гына алабыз. Иң яхшы очракта да 4 процент кына эләгә безгә, чөнки җырчылар керемнәренең күп өлешен яшерә.

– Корпоратив, интернетта яңгыраган җырларны контрольдә тотып бетерү тагын да авыррак тыр әле.

– Кызганыч, әммә интернет өчен җәмгыятьнең аккредитациясе юк. Корпоративларга да безнең бер генә агент та үтеп керә алмый. Аннан соң безнең агент-инспекторлар Казан, Чаллы, Түбән Кама һәм Әлмәт кебек зур шәһәрләрдә генә бар.

– Судларга кадәр барып җиткән очраклар да бар дип ишеткәнебез бар.

– Җырчыларның йөзләренә кызыллык китерә торган хәлләр турында сөйлисем килми, шулай да соңгы очрак турында әйтәм. Хәзер без, Башкортстан шагыйрәсе Гөлнара Рәшитова исеменнән, Элвин Грей белән бәхәсләшәбез. Җырчыдан бигрәк, аның администраторлары үзләрен бик оятсыз тота. Без аларга: «Әйдәгез, килешү төзик», – дип яздык. Алар, безнең бөтен җырлар сатып алынган, туп-туры композиторларга түлибез, диделәр. Әмма барып тикшергәч, закон бозуның биш очрагы ачыкланды. Әлегә дәгъва җибәрдек, әгәр аңа җавап килмәсә, судка мөрәҗәгать итәргә мәҗбүр булабыз. Элвин Грей» шәхси эшмәкәренә 500 мең сумга якын штраф яный. Түләми хәлләре юк, чөнки шәхси эшмәкәрлек үз милке белән җавап тота.

– Зөфәр әфәнде, дилбегә яңа җитәкчелек кулына тоттырылгач, җәмгыять нинди үзгәрешләр кичерә?

– Үзгәрешләр бар һәм алар бик җитди. Беренчедән, элек РАО кебек оешмалар җыйган акчаның 35 процентын үзләренә калдыра иде. Хәзер яңа закон проекты нигезендә, ул 25 процентка кадәр төшереләчәк. Бу авторларга бик файдалы булыр. Икенчедән, 28 апрельдә Мәскәүдә Россиядәге бөтен филиалларны (бүген 12 филиал эшли. – **З.С.**) бетерү мәсьәләсенә багышланган зур конференция уза. Киләчәктә вәкиллек кенә калдырылачак дип планлаштыралар. Бу үзгәрешләр нәтиҗәсендә аппарат та кыскартылачак. Татарстанда эшләүче 16 кешедән алты агент һәм өч хезмәткәр генә калыр дип уйланыла. Элек һәр агент төп оешмага филиал аркылы буйсынса, хәзер турыдан-туры Мәскәүгә буйсыначак. Моңа кадәр юристлар да, агентлар да барысы да безнең филиалда штатта иде, хәзер аларның һәрберсе шәхси эш ачып, мөстәкыйль эшләргә тиеш була. Хәзер безнең бурыч, бер агент белән икенчесе арасында каршылыклар килеп чыкмасын өчен, аларның эшләрен күзәтчелек кенә итү булып калачак. Моннан соң акчалар да туп-туры Мәскәүгә китә. Тагын бер яңалык: хәзер һәр автор өчен «шәхси кабинет» сервисы булдырылды. Монда бөтен мәгълүмат тупланып барылачак. Гомумән, РАОдагы әлеге яңалыклар авторлар мәнфәгатен күбрәк яклар һәм кайгыртыр, аларга тиешле гонорарны тулысынча түләр, дип өметләнәбез.

КҮҢЕЛЕҢ ТӨШМӘСЕН!

Психотерапевт Гомәр Зыятдинов депрессия турында

СӘЛАМӘТЛЕК

Өч-дүрт елдан депрессия эшли алмауга, сәләтсезлеккә китергән төп сәбәпләрнең берсе булуы бар, дип борчыла табиблар. Бүген Татарстан халкының яртысыннан артыгында депрессия билгеләре күзәтелә. Төшенкелек һәркемдә булырга мөмкин. Быел Бөтендөнья сәламәтлек көненең депрессия темасына багышлануы да шуңа бәйле. Без исә бу хакта Бехтерев исемендәге Республика психиатрия клиник хастаханәсенең психотерапия үзәге мөдире, Татарстанның атказанган табибы Гомәр Зыятдинов белән әңгәмә кордык.

Эльвира МОЗАФФАР

– Депрессия – беренче чиратта, авыру. Аның сәбәпләре берничә төрле: эндоген, ягъни кешенең эчке проблемалары белән бәйле; психоген, монысы тормышта килеп туган стресслар нәтиҗәсендә, төрле борчулардан, якыннарның үлеме, гаиләдәге фаҗигаләрдән соң килеп чыга. Шулай ук озакка сузылган соматик авырулар да көчле төшенкелеккә китерергә мөмкин. Әле беркөнне генә аягы, биле авыртудан зарланган яшь кенә хатын-кыз мөрәҗәгать итте. Мин анда депрессия билгеләре күрдем.

– Депрессиянең билгеләре нинди соң?

– Медицина терминнарына тукталмыйча гына, гади итеп әйткәндә, беренчедән, кеше рәхәтлек, канәгатьләнү хисе кичерми. Телевизор караса да, урамга чыкса да, ул – битараф. Икенчедән, хәлсезлек сизә. Өченчедән, кәефе булмый. Бу төп билгеләрдән тыш йокысызлык, аппетит булмау күзәтелергә мөмкин. Кешеләрдән еш кына, авызымның тәме юк, дигәнне ишетергә туры килә. Яки киресенчә, кеше төнлә торып күп итеп ашарга мөмкин. Көчәнә, мөмкинлекләреңә ышанмау, үзеңне түбән бәяләү, һәрчак үзеңнән гаеп эзләү, кирәксез, файдасыз дип тою, җенси теләк кимү – болар барысы да авыру билгеләре. Әгәр кешедә бу билгеләрнең икесе, өчесе ике атна дәвамында күзәтелсә, депрессия диагнозын куярга җирлек бар. Ә бер көн начар булып, ике көн кеше яхшы кәеф белән йөри икән, бу бернинди дә депрессия түгел, күңел төшенкелеге генә.

– Скандинавиянең кайбер илләрендә, депрессияне кисәтү өчен, кешеләрне махсус бүлмәләрдә дәвалыйлар икән дип ишеткәнем бар. Анда организмга кояш нуры кебек тәэсир итә торган яктыртылган утлар куела икән. Кояш депрессиядән саклыймы?

– Әйе, юкка гына көзге-кышкы депрессия турында әйтмиләр. Кояш нурлары азайгач, кешедә мелатонин гормоны күбрәк бүленеп чыга башлый. Нәтиҗәдә кешенең һаман йоклыйсы килә, ул хәлсезләнә, күп ашый. Шуңа да кояшлы көндә урамда күбрәк булырга кирәк. Язга таба кояш нурлары җитмәү проблемасы үзеннән-үзе бетә.

– Дөнья куабыз, чабабыз, тормыш темпы тизләнә бара. Көн саен мәшәкатьләре дә чыгып кына тора. Депрессия белән авыручыларның артуы гаҗәп тә түгел. Бу авыруның аяныч нәтиҗәләргә китерүе борчый.

– Статистика буенча төгәл генә мәгълүматлар юк. Шулай да республика халкының яртысыннан артыграгында депрессия күзәтелә дип әйтергә була. Күпләр үзләренең хәлсез булуын йөрәк, баш авыртуы белән бәйли, депрессия дип уйламыйлар да. Кайберәүләр табибка барырга, үз хәлен сөйләргә ояла, кемдер курка. Дөрес, соңгы елларда психотерапевтларга ачылучы пациентлар артты. Авыр хәлдәге авыруларга антидепрессантлар язабыз. Кеше ул дару төймәләренә күнекми, ияләнми, берникадәр вакыттан соң хәле яхшыргач, аларны эчмичә дә яши ала. Ә менә вакытында дәваланмасаң, депрессия инфаркт, инсульт, ашказаны җәрәхәте китереп чыгарырга, гаилә, шәхси тормыш җимерелүгә, эш урынын югалтуга китерергә мөмкин. Иң куркынычы – кешенең үз-үзенә кул салуы.

– Бөтен авырулар нервыдан диюләре хак икән алайса. Ә менә балаларда депрессия күзәтеләме?

– Гадәттә, депрессия 25 яшьтән соң ешрак күзәтелә, шуңа да карамастан балаларда да була. Безнең хастаханәдә махсус балалар психотерапевты да бар. Үсмерләрнең тәртипләре бозыла, начар укый башлыйлар, мәктәпкә йөрмиләр, дәрестән качалар, сугышалар, бәхәсләшәләр. Кечкенә сабыйларда депрессия билгеләре елау, урын-җиргә сию, төнлә куркып уяну кебек күренешләрдә чагыла. Кыскасы, балалар үзләренчә стресс кичерә, аларның үз депрессияләре.

– Компьютер, заманча гаджетлар да тәэсир итәдер. Күп балалар интернетсыз тормышны күңелсез дип саный бит.

– Бүген компьютерсыз яшәп булмый. Интернет аша дуслар табарга, белемне арттырырга, мәгълүмат алырга була. Ләкин виртуаль тормыштан аерылып шул дуслар белән очрашу, тере аралашу файдалы. Компьютер, телефонның файдалы якларын эзләргә кирәк. Вакытын, тормышын дөрес планлаштыра алмаган кешеләр авыруга сабышырга мөмкин.

– Шоколад ашау кәефне күтәрә, диләр. Депрессияне билгеле бер ризыклар ашап җиңеп буламы?

– Шоколад күп ашау – шикәр авыруына, тынычландыра торган үлән чәйләрен гел эчү аллергиягә дә китерергә мөмкин. Бу күпмедер дәрәҗәдә шартып әйтелгән сүзләр. Шулай да чик-чаманы белергә кирәк. Иң мөһиме – эчке халәтеңне үзгәртү.

Депрессиягә бирешмәс өчен психотерапевт Гомәр Зыятдинов киңәшләре

- ✓ Яшәү рәвешен үзгәртегез, билгеле бер режим булдырыгыз.
- ✓ Ял кирәк, әмма бу көне буе йоклап яту дигән сүз түгел.
- ✓ Табигатькә чыгыгыз.
- ✓ Кояш нурларын күбрәк тоярга тырышыгыз.
- ✓ Бертөрлелектән качарга тырышыгыз.
- ✓ Тик утырмагыз, үзегезгә яңа шөгыльләр уйлап чыгарыгыз.
- ✓ Физик активлык кирәк.
- ✓ Наркотик, спиртлы эчемлекләр куллану кебек начар гадәтләрдән ерак торыгыз.
- ✓ Дуслар, туганнар, якыннарыгыз белән ешрак аралашыгыз.
- ✓ Конфликтлы хәлләрдән качарга тырышыгыз.

БӘХЕТ ӨЧЕН КҮП КИРӘКМИ

СЕРАТОНИН
(бәхет, шатлык гормоны)

Кояш җылысында, тиешенчә йоклаганда, чамасын белеп баллы ризыклар, банан, хөрмә, чикләвек ашаганда, физик активлык вакытында барлыкка килә.

ЭНДОРФИН
(«авыртуны баса торган» гормон)

Ешрак көлгәндә, сәнгатькә тартылганда: театрга, күргәзмәләргә йөргәндә, комедия караганда, B, C, фосфор, цинкка бай ризыклар ашаганда бүленеп чыга.

ДОФАМИН
(канәгатьләнү гормоны)

Балыкта, сөтле ризыкларда, яшел, әфлисун төсендәге яшелчә, җиләк-җимештә, кара шоколадта, B_6 витаминында бар.

10 АПРЕЛЬ– ДҮШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Дорога в пустоту» . Телесериал (16+)
10:00 Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Ветреная женщина». Телесериал (16+)
13:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
14:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Без тарихта эзлебез» (6+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Тайна Армана». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Любовью Лукиной » (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:05 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Татарлар» (12+)
11:30 «Белем дөньясы» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Тамчы-шоу» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Халкым минем» (12+)
19:40 «Туган җир» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Шагыйрьләрдән дә шагыйрьрәк». Айрат Арсланов (6+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Парламентские вести»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Налет». (16+)
23.30 «Вечерний Ургант» . (16+)

РОССИЯ 1
05.00 Утро России.
09.00 Вести.
09.15 Утро России.
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-12». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Торгсин». (12+)
22.10 Т/с «Торгсин». (12+)
23.15 Специальный корреспондент. (16+)

11 АПРЕЛЬ– СИШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Музыкаль каймак» (12+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Дорога в пустоту » . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Туган җир» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Ветреная женщина». Телесериал (16+)
13:00 «Путь» (12+)
13:15 «Рыцари вечности» (12+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:15 «Дорога без опасности» (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Тайна Армана». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 Волейбол. Кубок ЕКВ. Финал. «Динамо-Казань» -«Юнет Ямамай» (Бусто-Арсицио, Италия). Трансляция из Казани. По окончании - Татарстан хәбәрләре (6+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Сарией Сабурской» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Башваткыч» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Язмышлардан узмыш юк икән». Телефильм. Беренче серия (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Рядовые России»
9.20 «Дороже богатства»
9.40 «Кандидаты на соискание Государственной премии Республики Татарстан им. Г.Тукая»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Налет». (16+)
23.35 «Вечерний Ургант» . (16+)

РОССИЯ 1
05.00 Утро России.
09.00 Вести.
09.15 Утро России.
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-12». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Торгсин». (12+)
22.10 Т/с «Торгсин». (12+)
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

12 АПРЕЛЬ– ЧӘРШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Таяну ноктасы» (16+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Дорога в пустоту» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Ватандашлар». Телефильм (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Ветреная женщина». Телесериал (16+)
13:00 «Каравай» (6+)
13:30 Документальные фильмы (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Тайна Армана». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
17:30 «Трибуна «Нового Века» (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Гией Эрадзе» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Әдәби хәзинә» (12+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:15 «Башваткыч» (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Туган җир» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Без тарихта эзлебез» (0+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Язмышлардан узмыш юк икән». Телефильм. Икенче серия (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Налет». (16+)

РОССИЯ 1
05.00 Утро России.
09.00 Вести.
09.15 Утро России.
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-12». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Торгсин». (12+)
22.10 Т/с «Торгсин». (12+)
23.15 «Вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

13 АПРЕЛЬ– ПӘНҖЕШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Башваткыч» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник» (12+)
09:00 «Дорога в пустоту» . Телесериал (16+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 « Ветреная женщина». Телесериал (16+)
13:00 «Адымнар» (0+)
13:30 Документальный фильм (12+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Әдәби хәзинә» (12+)
15:40 Мультфильмы (0+)
16:00 «Тайна Армана». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Татарлар» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Таяну ноктасы» (16+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «Вечерняя игра» с Ильдаром Хайруллиным» (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Без тарихта эзлебез» (0+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
10:10 «Ай нурында туган моң». Римма Ибраһимова турында телеочерк (6+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Яшьләр тукталышы» (12+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Әдәби хәзинә» (12+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Таяну ноктасы» (16+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Оныта алмыйм». Ретро-концерт (0+)
22:40 «Язмышлардан узмыш юк икән». Телефильм. Өченче серия (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Национальный вопрос и ответ»
9.20 «Современник». Мирхайдар Файзи
9.50 «Город мастеров»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20, 20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 «Давай поженимся!» (16+)
18.00 Прямой информационный канал «Первая Студия». (16+)
20.00 «Пусть говорят» с Андреем Малаховым. (16+)
21.00 Время.
21.35 Т/с Премьера. «Налет». (16+)

Яучы, 1000 сум. Тел.: **89872669855**
реклама

РОССИЯ 1
05.00 Утро России.
09.00 Вести.
09.15 Утро России.
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-12». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 Т/с «Торгсин». (12+)
22.10 Т/с «Торгсин». (12+)
23.15 «Поединок». Программа Владимира Соловьёва. (12+)

14 АПРЕЛЬ– ҖОМГА

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 «Халкым минем...» (12+)
05:25 «Нәсыйхәт» (6+)
05:50 Татарстан хәбәрләре (12+)
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:00 Новости Татарстана (12+)
08:10 «Народный будильник » (12+)
09:00 Документальный фильм (12+)
10:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
10:50 «Нәсыйхәт» (6+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Йөрәктән-йөрәккә». Композитор Рөстәм Яхин (6+)
13:00 «Башваткыч» (6+)
14:00 «Актуальный ислам» (6+)
14:15 «Все суры Корана» (6+)
14:30 Новости Татарстана (12+)
14:45 «Хочу мультфильм!» (0+)
15:00 «Кучтәнәч» (0+)
15:15 «Тамчы-шоу» (0+)
15:40 Мультфильмы (0+)
15:50 «Зебра» (0+)
16:00 «Тайна Армана». Телесериал (12+)
17:00 «Икенче туй». Телесериал (12+)
18:00 «Туган җир» (12+)
18:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
19:00 «Белем дөньясы» (6+)
19:30 Новости Татарстана (12+)
20:00 «Вызов 112» (16+)
20:10 «Тукай урамында» (0+)
20:15 «Кучтәнәч» (0+)
20:30 Татарстан хәбәрләре (12+)
21:00 «Кичке аш» (6+)
21:30 Новости Татарстана (12+)
22:00 «Вызов 112» (16+)
22:10 «ДК» (12+)
22:30 «Выходные!». Художественный фильм (16+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
08:05 «Нәсыйхәт» (6+)
08:30 «Яшәсен театр!» (0+)
09:00 «Яңалыклар» (12+)
09:20 «Музыкаль каймак» (12+)
10:10 «Ком сәгате» (12+)
11:05 «Татарлар» (12+)
11:30 «Кичке аш» (6+)
12:00 «Яңалыклар» (12+)
12:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
13:10 «Караоке татарча» (0+)
13:25 «Нәсыйхәт» (6+)
14:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
14:30 «Переведи! Татарча өйрәнәбез» (0+)
15:00 «Яңалыклар» (12+)
15:15 «Кучтәнәч» (0+)
15:30 «Поем и учим татарский язык» (0+)
15:45 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
16:00 «Утканнар сагындыра» (0+)
16:10 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы (6+)
18:00 «Яңалыклар» (12+)
18:20 «Икенче туй». Телесериал (12+)
19:10 «Ай нурында туган моң». Римма Ибраһимова турында телеочерк (6+)
20:05 «Татарлар» (12+)
20:30 «Ватандашлар» (6+)
21:00 «Яңалыклар» (12+)
21:20 «Кучтәнәч» (0+)
21:40 «Караоке татарча» (0+)
21:55 «Музыкаль каймак» (12+)
22:45 «Язмышлардан узмыш юк икән». Телефильм. Дүртенче серия (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
6.05, 7.05, 8.05 «Вести – Татарстан. Погода»
6.35, 7.35, 8.35 «Вести – Татарстан. Утро»
9.00 «Иҗат»
9.25 «Алтын куллар»
11.40 «Вести – Татарстан»
14.40 «Яңалыклар. Татарстан»
17.20 «Вести Приволжского федерального округа»
20.45 «Вести – Татарстан»

ПЕРВЫЙ
05.00 Телеканал «Доброе утро».
09.00 Новости.
09.20 Контрольная закупка.
09.50 «Жить здорово!» (12+)
10.55 Модный приговор.
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Наедине со всеми». (16+)
13.20 «Время покажет». (16+)
15.00 Новости с субтитрами.
15.15 «Время покажет». (16+)
16.00 «Мужское / Женское». (16+)
17.00 Жди меня.
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.45 «Человек и закон» с Алексеем Пимановым. (16+)
19.50 «Поле чудес». (16+)
21.00 Время.
21.30 «Голос. Дети». Новый сезон.

РОССИЯ 1
05.00 Утро России.
09.00 Вести.
09.15 Утро России.
09.55 «О самом главном». (12+)
11.00 Вести.
11.40 Вести. Местное время.
11.55 Т/с «Склифосовский». (12+)
13.00 Т/с «Склифосовский». (12+)
14.00 Вести.
14.40 Вести. Местное время.
14.55 Т/с «Тайны следствия-13». (12+)
16.00 Т/с «Тайны следствия-13». (12+)
17.00 Вести.
17.20 Вести. Местное время.
17.40 «Прямой эфир». (16+)
18.50 «60 минут». (12+)
20.00 Вести.
20.45 Вести. Местное время.
21.00 «Юморина». (12+)
23.20 Х/ф «Будущее совершенное». (12+)

15 АПРЕЛЬ– ШИМБӘ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Автомобиль» (12+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Халкым минем...» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Каравай» (6+)
12:30 «Видеоспорт» (12+)
13:00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
13:30 «Созвездие – Йолдызлык-2017» (0+)
14:30 «Шулай яшим...». Шагыйрь Рафис Корбанның 60 яшьлек юбилей кичәсе (6+)
16:30 «Татарлар» (12+)
17:00 «Без тарихта эзлебез» (6+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Җыр ул – хисләр балкышы». Наил Касыймов (6+)
19:00 Документальный фильм (12+)
19:30 Новости в субботу (12+)
20:00 «Адымнар» (12+)
20:30 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:30 Новости в субботу (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 «Гөлнарага дүрт кияү». Гөлнара Габидуллина концерты (6+)
07:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
09:30 «Шаян хәлләр» (16+)
10:00 «Кайнар хит» (12+)
11:00 «Башваткыч» (6+)
11:50 «Җырлыйк әле!» (6+)
12:45 «Яшьлегем сукмагы». Алинә Сафиуллина концерты (6+)
14:30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» (12+)
15:00 «Sиңа Миннән Sәлам» (6+)
17:30 «Нәсыйхәт» (6+)
18:00 «Идрис Газиев тәкъдим итә. Сәйдәш театры» (6+)
18:55 «Кичке аш» (6+)
19:20 «Башваткыч» (6+)
20:10 «Җырлыйк әле!» (6+)
21:00 «Адымнар» (12+)
21:30 У.Гибсон. «Могҗизадан соң». К.Тинчурин исемендәге Татар дәүләт драма һәм комедия театры спектакле (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
8.00, 11.20 «Вести – Татарстан»
8.20 «Доброе утро, Татарстан!»

ПЕРВЫЙ
04.45 Х/ф «Укрощение огня». (12+)
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Укрощение огня». (12+)
08.00 Играй, гармонь любимая!
08.45 М/с «Смешарики. Новые приключения».
09.00 Умницы и умники. (12+)
09.45 Слово пастыря.
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 Д/ф «Алексей Леонов. Первый в открытом космосе».
11.20 Смак. (12+)
12.00 Новости с субтитрами.
12.15 «Идеальный ремонт».
13.15 «На 10 лет моложе». (16+)
14.00 «Голос. Дети».
15.50 Премьера. «Вокруг смеха».
18.00 Вечерние новости с субтитрами.
18.15 «Кто хочет стать миллионером?» с Дмитрием Дибровым.
19.10 «Минута славы». Новый сезон.
21.00 Время.

РОССИЯ 1
05.15 Т/с «Чокнутая». (12+)
07.10 «Живые истории».
08.00 Вести. Местное время.
08.20 Россия. Местное время. (12+)
09.20 Сто к одному.
10.10 «Пятеро на одного».
11.00 Вести.
11.20 Вести. Местное время.
11.40 «Измайловский парк». Большой юмористический концерт. (16+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Сердечная недостаточность». (12+)
16.20 «Золото нации».
18.00 Субботний вечер.
20.00 Вести в субботу.
21.10 Х/ф «Рай». (16+)

16 АПРЕЛЬ– ЯКШӘМБЕ

ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР
05:00 Концерт (6+)
08:00 «Адымнар» (12+)
08:30 Мультфильмы (0+)
09:00 «ДК» (12+)
09:15 Документальный фильм (12+)
09:45 «Тамчы-шоу» (0+)
10:15 «Яшьләр тукталышы» (12+)
10:45 «Музыкаль каймак» (12+)
11:30 «Секреты татарской кухни» (12+)
12:00 «Быть оракулом...». Телеочерк о композиторе Софье Губайдуллиной (6+)
12:30 «Каравай» (6+)
13:00 «Закон. Парламент. Общество» (12+)
13:30 «Адымнар» (12+)
14:00 «Созвездие - Йолдызлык-2017» (0+)
15:00 «Ком сәгате» (12+)
16:00 «Җырлыйк әле!» (6+)
17:00 «Видеоспорт» (12+)
17:30 «Әдәби хәзинә» (12+)
18:00 «Башваткыч» (6+)
19:00 Телефильм (12+)
19:30 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)
20:30 «Болгар радиосы» концерты (6+)
21:30 «Кичке аш» (6+)
22:00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа (12+)

«ТНВ-ПЛАНЕТА»
06:00 Файзи Гаскаров исемендәге Башкорт дәүләт халык бию ансамбле концерты (6+)
07:50 «Могҗиза көткәндә». Динар Бәдретдинов концерты (6+)
09:25 «Яшьләр тукталышы» (12+)
09:55 «Тамчы-шоу» (0+)
10:20 «Поем и учим татарский язык» (0+)
10:30 «Җырлыйбыз да биибез» (0+)
11:00 «Белем дөньясы» (6+)
11:30 «Халкым минем» (12+)
12:00 Җырлый Бәширә Насыйрова (6+)
12:30 «Татарлар» (12+)
13:00 «Нәсыйхәт» (6+)
13:30 «Мунча морҗасы». «Мунча ташы» татар эстрада театры спектакле (12+)
16:30 «Музыкаль каймак» (12+)
17:20 «Әдәби хәзинә» (6+)
17:50 «Без тарихта эзлебез» (0+)
18:20 «Болгар радиосы» концерты (6+)
19:10 «Ком сәгате» (12+)
20:05 «Җырларым яшәтсен, яшәртсен иде». Раяз Фасыйхов концерты (6+)
22:35 «Шаян хәлләр» (16+)
23:20 «Халкым минем» (12+)

«РОССИЯ1 – ТАТАРСТАН»
10.20 «Вести – Татарстан. События недели»

ПЕРВЫЙ
06.00 Новости.
06.10 Х/ф «Доброе утро».
08.05 М/с «Смешарики. Пин-код».
08.25 «Часовой». (12+)
08.55 «Здоровье». (16+)
10.00 Новости с субтитрами.
10.15 «Непутевые заметки» с Дмитрием Крыловым. (12+)
10.35 «Пока все дома».
11.25 Фазенда.
12.00 Новости с субтитрами.
12.10 Премьера. «ТилиТелеТесто» с Ларисой Гузеевой.
13.35 Д/ф «Теория заговора». (16+)
14.25 Д/с «Романовы» . (12+)
16.35 «ДОстояние РЕспублики: Алла Пугачева».
18.30 «Аффтар жжот». (16+)
19.30 Премьера. «Лучше всех!»
21.00 Воскресное «Время».
22.30 «Клуб Веселых и Находчивых». Высшая лига. (16+)

РОССИЯ 1
04.45 Х/ф «Я буду рядом». (12+)
07.00 Мульт-утро.
07.30 «Сам себе режиссёр».
08.20 «Смехопанорама» Евгения Петросяна.
08.50 Утренняя почта.
09.30 Сто к одному.
10.20 Местное время. Вести-Москва. Неделя в городе.
11.00 Вести.
11.20 «Смеяться разрешается».
13.10 «Семейный альбом». (12+)
14.00 Вести.
14.20 Х/ф «Запах лаванды». (12+)
18.00 «Танцуют все!»
20.00 Вести недели.
22.00 «Воскресный вечер с Владимиром Соловьёвым». (12+)

Первый, Россия1 каналларының программасы «Сервис-ТВ» АҖдан алынды

«ТАТАРСТАН» радиосы

10 АПРЕЛЬ – ДҮШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35, 18.10 Яңалыклар. Новости
6.45 «Юллар чатында»
6.50,7.50,10,55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00, 11.00-12.10, 13.00-13.10, 14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.00, 13.10 Александр Галин. «Сагыш». Г.Камал ис.ТДАТ спектакле. 1-2нче өлешләр
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
18.25 «Сердәшхана»
18.40 «Җыр – минем гомерлек юлдашым».

11 АПРЕЛЬ – СИШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Актуальное интервью»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Пар канатлар»
12.10 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 «Җыр җиргә язлар китерә». Рәшит Әхмәтҗан шигырьләренә язылган җырлар

12 АПРЕЛЬ – ЧӘРШӘМБЕ

6.00-8.00 «Яңа көн». Вакыйгалар панорамасы
6.04 «Нефть чыккан якларда»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,10.55,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Актуальное интервью»
10.35 «Старт»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Яшьлек аланы»
18.25 Вәис Бәйрәмов җырлары

13 АПРЕЛЬ – ПӘНҖЕШӘМБЕ

6.00-8.00 «Новый день». Панорама событий
6.04 «Перекресток»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00 Вести радио России
7.10 Диалог в прямом эфире
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Доброе братство лучше богатства» (на чувашском языке)
10.35 «Время молодых»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 «Офыклар»
18.25 Заһид Хәбибуллин әсәрләре

14 АПРЕЛЬ – ҖОМГА

6.00-8.00 «Иртәнге нур»
6.15 «Музыкаль мизгелләр»
6.35,10.00,13.10,18.10 Яңалыклар. Новости
6.50,7.50,13.55,18.55 Реклама, прогноз погоды
7.00-7.10 Вести радио России
7.10 Туры элемтә
8.00-10.00,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-18.10,19.00 Трансляция радио России
10.10 «Вдохновенья миг»
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.20 Концерт
18.25 Галия Гафиятуллина һәм Габдулла Рәхимкулов язмалары

15 АПРЕЛЬ – ШИМБӘ

10.10 «Табигать дуслары»
10.30 «7 көн». Атналык күзәтү
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10,16.00 Трансляция радио России
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында». Язучы Ибраһим Газины искә алу кичәсеннән язма. 1нче кисәк
13.10 Татар халык көйләре
15.10 Язучы Ибраһим Газины искә алу кичәсеннән язма. 2нче кисәк

16 АПРЕЛЬ – ЯКШӘМБЕ

8.00-9.00 «Между Волгой и Уралом». Объединенный радиожурнал семи республик
9.00-10.10,11.00-12.10,13.00-13.10,14.00-15.10,16.00-16.10,17.00 Трансляция радио России
10.10 «Көмеш кыңгырау»
10.30 «7 дней». Обзор событий
10.55,13.55 Реклама, прогноз погоды, программа передач
12.10-13.00 «Татарстан дулкынында»
13.10 Ял концерты
15.10 «Тел күрке – сүз»
15.35 Кыска хикәяләр

КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

- Биш кешенең икесе үзенең беренче мәхәббәтенә өйләнә.
- Иң кыска буйлы кешеләр – японнар.
- Иң озын буйлылар – голландияләр.
- Балалар көненә уртача 400 тапкыр көлсә, олылар – нибары 15 тапкыр.
- Бер айдан өч айга кадәрге балалар күз яшьләрсез генә елый.
- Зәңгәр күзләләр караңгыда яхшырак күрә.
- Кеше гомеренең биш елын ашап уздыра.
- Кешенең тәкерәген гомере буена җыеп барсаң, аның белән уртача зурлыктагы бер бассейнны тутырып булыр иде.
- Дөньяда иң киң таралган исем – Мөхәммәд.
- Ир балалар күбрәк көндез туа, кыз балалар – төнлә.
- Иң күп чәй эчүчеләр – инглизләр, алар америкаларга караганда, чәйне егерме тапкыр күбрәк эчә. Ә без чәйне иң күп эчүчеләр татарлар дигән булабыз.
- Йөз яшькә җитүчеләрнең 80 проценты – хатын-кызлар.
- Дөньяда һәр өч секунд саен бала туа.
- Кеше гомере буена уртача 27 тонна ризык ашый, бу – җиде фил авырлыгына тиң.
- Америкада иң куркыныч һөнәр – Аляскада краб тоту.
- Мона Лизаның кашлары юк, ул вакытта Флоренциядә кашны кыру модада булган.
- Йортны тизрәк һәм кыйммәткәрәк сату өчен, аны сары төскә буярга кирәк.
- һәр секунд саен Америкада 45 кг шоколад ашала.

www.shahrikazan.com
vk.com/shahrikazanda
facebook.com/shahrikazan
twitter.com/shahri_kazan
ok.ru/shrikazan
instagram.com/shahrikazan

СКАНВОРД

Дивар уты; Оча торган тәлинкә; Хатынның сеңелкәше; Мәркәзе – Мәскәү шәһәре; Югары сыйфатлы тыгыз кәгазь; Крепость тирәли казылма; Гранат; Европа дәүләте; Татарстандагы шәһәр; Автобуслар ясый торган көнлек рейс; Аризона яки Индиана; Елтырый торган җепле тасма; Үлән сүле; Гөлчәчәк; Кыр суганы; Чатан; Иделнең борынгы атамасы; Нәрсәнедер кая да булса урнаштыру; Җәза; Сыр сорты; Үзеннән өлкән ир кеше; Нәзек; Татар хатын-кызлары исеме; Йөзнең сакал үсә торган урыны; Хачатурян; Японияне беренче башкаласы; Прәшкә; Симез; Очкыч; Судно борты; Испания актеры Антонио; Мордовия башкаласы; Дистанция; Итек; Юнәлеш; ДТ; Татарстан Республикасы; Атка дәшү; Мырау батырның хуҗасы; Пермь футбол клубы; Элемтә операторы; Утын өеме; Күңел салу; Урманның агачлар бик куе үскән урыны; Пляж тулы; Корабта пешекче; Тәнәфес; Казахстан башкаласы; Юешлек; Кама елгасы кушылдыгы; Кыска итәк; Атлас; Нота; Хәрәкәт итү әгъзасы; Клавишлы бик зур музыка коралы; Кайбер югары уку йортларының исеме; Физикада тыгызлыкның аңлатма; Дистә; Винни-Пухның дусты; Татар дәүләт курчак театры; Теш ите; Яктылык чыганагы; 100 м²; Абдулла Алиш әкияте; Актриса ... Миклош; Кисәкчә

Фаил Гаязов төзеде

Горизонталь буенча: Сәфәров, бра, балдыз, НЛО, сут, роза, маршрут, Ила, кую, Сания, Нара, ага, газап, ката, юан, «Амкар», ешлык, ара, ял, Астана, Рөстәм, кок, аяк, орган, дым, академия, «Әкият», ро, ар, урт, ут, «Нечкәбил», Анна, Атлас.

Вертикаль буенча: Саранск, Ризван, МТС, ияк, Россия, әрдәнә, Арам, Ык, ватман, мини, аксак, ур, Ра, ошату, штат, як, анар, ael, карта, ука, до, Португалия, ун, юа, ком, та, юка, Иа, Алабуга, солярка, Ан, ТР, лаг, на, Зәйнәп, Бандерас.

Юмор хисе

Юмор хисе мәхәббәт кебек, йә бар ул, йә – юк. Булса да кыен диләр. Кемдер, әйтик, шаярткан була – кешеләргә елмаю бүләк итәргә тели, ә аны аңламыйлар. Мыскыл итә дип уйлыйлар һәм кыйнап ташлыйлар.

Миндә юмор хисе юк. Мин җитди кеше. Беркемгә дә елмаю бүләк итәргә теләмим. Шаяртмыйм да, шаярта да белмим. Гел дөресен әйтәм. Әйтик, мин кибеткә керәм дә:

– Зинһар өчен колбаса бирегез әле, – дим.

Сатучы елмаймсын өчен «матурым» дип тә өстәмим. Намус җитми. Ну, кайсы төше матур инде? Аның матурлыгын эзләп табар өчен, тарихчы булырга кирәк. Ул да мине матур дими. Тик елмайган була. һәм сорый:

– Сезгә күпме кирәк?

– Егерме биш сантиметр.

Бу – юмор түгел. Минем кечкенә сумкага бары тик егерме биш сантиметр гына колбаса сыя. Тик сатучы аптырабрак кала. Баштанаяк миңа күз йөгертеп ала – безупречно. Күзгә карый:

– Ә җитдирәк булсак?

– Җитдирәк булсак та – егерме биш сантиметр.

– Гафу итегез… Тик без сантиметрлап үлчәмибез… – һәм өстәп куя: – Колбасаны.

Юмор хисе булган кеше елмаер да ары китәр иде. Мин алай итмим. Мин сумкамнан линейка алам. Нәкъ егерме биш сантиметр зурлыктагы. Сатучы миңа сәерсенеп карый да эшкә тотына. Бик җентекләп, ялгышмаска тырышып үлчи. Халыкта «җиде кат үлчә, бер кат кис» дигән әйтем бар бит. Сатучы бу әйтемне бик яхшы белә бугай. Ул арада кечкенә чират хасил була. Барысы да аның линейка белән колбаса үлчәгәнен күзәтә. Бертын карап торгач, бер ханым чиратны ташлап китә. Янымда торган ир пышылдый:

– Нәрсә, монда сантиметрлап саталармыни?

– Әйе, – дим мин.

– Карале, кызык икән, – ди аның артында торган ханым. – Мин дә алыйм әле алайса.

Ниһаять, сатучы эшен бетерә. Кисә һәм тагы бер кат үлчи. Миңа карый:

– Егерме дүрт сантиметр ярым булса ярыймы?

– Ярый. Рәхмәт.

Сатучы колбасаны үлчәмгә сала – авырлыгын да белергә кирәк бит һәм аны төреп бирә. Линейканы да суза.

– Юк, рәхмәт. Үзегезгә калсын. Мин бит монда гел килеп йөрим.

һәм читкәрәк китеп, колбасаны сумкага җайлап урнаштырам. Ул арада минем артта торган баягы ирнең тавышы ишетелә:

– Миңа да шул колбасаны бирегез әле.

– Күпме бирим? – ди сатучы. Тавышында миннән котылу ләззәте сизелеп кала.

Ир беркадәр уйланып тора:

– Ну-у… Бер утыз сантиметр булса…

Хатын аңа сәерсенеп карап ала да, бәхәсләшеп тормый, мин калдырган линейкага үрелә. Шулай да бер арада минем якка ымлап ала:

– Әллә сез бергәме?

Миңа кызык. Күзәтәм. Ир дә миңа күз атып ала:

– Юк инде.

Беркадәр маташканнан соң, сатучы башын күтәрә:

– Утыз биш сантиметр.

– Яхшы.

Сатучы үлчәп, төреп бирә. Ир акча түләп ары киткәч, җиңел сулап куя:

– Уф, әллә кемнәр бар бу дөньяда, – һәм чиратта торган ханымга борыла: – Сезгә нәрсә иде?

– Ипи, сөт.

Сатучы алып бирә. Хатын бераз уйланып тора:

– Теге колбасагызны да бирмәссез микән?

– Яхшы. Күпме үлчим?

– Миңа да шул утыз биш сантиметр тирәсе инде…

Марат КӘБИРОВ.

Татарстан картасы

– Мәзәккә әйләнеп беткән бу тарих болайрак булган, – дип сөйләп китте пенсиядәге укытучы Нәзлия апа, – икенче төрлерәген ишеткән булсагыз, гаеп итмәгез – күпмегә алдым, шуңа сатам. Башкортстанның район мәгариф бүлегендә инспектор булып эшләүче Шәйхуллин дигән иптәшне кышкы буранлы көннәрнең берсендә, уку-укыту торышын тикшереп кайтыр өчен, авыл мәктәбенә җибәргәннәр. Ул заманнарда мәгариф бүлегенең иң шәп һәм, әйтергә кирәк, бердәнбер транспорты булып ат исәпләнгән. Толыпка төренеп утырган Шәйхуллинны кучер, таң атмас борын ук, ачы караңгыда мәктәпкә китереп куйган. Үзе, кич килеп алырга тиеш булып, кире районга кайтып киткән. Инспектор, көне буе тиешлесен тикшереп анализ ясаганнан соң, тамак ялгап, кайтыр юлга җыена башлаган.

Мәктәптән чыгып барганда, Шәйхуллинның күзе коридорда эленеп торган картага төшкән. Караса, стенада Татарстан картасы эленеп тора! Инспекторның күзе маңгаена менә язган! Тавышына шактый гына усаллык чаткылары кертеп: «Нишләп стенада Татарстан картасы эленеп тора?» – дип, озатып чыгып килүче мәктәп директорына сорау биргән. Директор, инспекторның бу соравына бераз аптырабрак: «Мәктәбебез Татарстан Республикасы территориясендә булгач, Татарстан картасы эленеп торырга фарыздыр инде», – дип җавап биргән. Шәйхуллин берни аңламый, һаман үзенекен сөйли икән: «Ничек Татарстан Республикасы территориясендә? Немедленно алыштырыгыз!» Баксаң, кучер, буранлы караңгы иртәдә юлны бутап, инспекторны, Башкортстан авылындагы мәктәп урынына, күрше Татарстан авылы мәктәбенә илтеп куйган булган икән. Менә сиңа Татарстан картасы!

Люция ӘБЛИЕВА.

5 мәзәк

– Ничек анда безнең Вәли?

– Әй… Беткән инде – импотентка әйләнде.

– Кирәк бит, ә? Югыйсә ничек яхшы укый иде!

* * *

Өенә кайтып кергән әнисе – улына:

– Спорт кибетенә ике потлы герләр чыккан. Син эзләгән идең түгелме?

Улы:

– Ә нишләп алмадың?

* * *

Базарда бер әби яшь кенә сатучы егеткә:

– Әй энем, бу куяның бигрәк кечкенә бит, аны суярга ничек кулың күтәрелде?

– Кем әйтте суйды дип? Суймадым! Ул үзе үлде…

* * *

– Сөеклем, миңа берәр матур сүз әйт әле…

– Сал, әйдә…

* * *

– Иванов!

– Мин!

– Синең күзең яхшы күрәме?

– Яхшы күрә, иптәш полковник.

– Әнә тегендә урман буенда сугышчылар окоп казыйлармы?

– Казыйлар.

– Ничә кеше?

– Ун солдат һәм бер прапорщик.

– Берсе прапорщик икәнен каян белдең?

– Чөнки ул казымый, карап кына тора.

ТАШКА БАСКАН

✓ Яхшылык начарлыкны һәрвакыт җиңә, димәк, кем җиңә – шул әйбәт.

* * *

✓ Иртә – хәерле, көн – файдалы, кич истәлекле булырга тиеш.

* * *

✓ Кешенең күзен ачсаң, авызын ябу кыен була.

* * *

✓ Сынамыш: гырлаган кеше беренче йоклап китә.

* * *

✓ Уңышка ирешүнең иң кыен өлеше – шатланырлык кеше табу.

* * *

✓ Яшь һәм зифа булып күренергә теләсәң, карт һәм юан кешеләр тирәсендә йөр.

* * *

✓ Бозлавык урында зыялылар саны бермә-бер кими.

* * *

✓ Дөрес ташланган тәмәке төпчеге зур янгынга сәбәпче була ала.

* * *

✓ Күседән курыккан ханым арысланны бәреп егарга мөмкин.

* * *

✓ Үз бәхетеңнең кыйпылчыкларыннан да ныграк кадала торган нәрсә юк.

* * *

✓ Балалар – тормыш чәчәкләре. Гөлләмәләр җый да әниеңә бир.

* * *

✓ Ходай да юмор ярата. Бигрәк тә һава торышы күзәтүләрен.

«ШӘҺРИ КАЗАН» – СИНЕҢ ӨЧЕН, СИНЕҢ ТУРЫНДА 8 (917) 851–69–62

Шәһри Казан
ИНДЕКСЛАР
П2395 (3 тапкыр чыга)
П2430 (пәнҗешәмбе саны)
П2419 (оешмалар өчен)
www.shahrikazan.com

ГАМӘЛГӘ КУЮЧЫ (НӘШЕР ИТҮЧЕ) – «ТАТМЕДИА» АҖ
«ТАТМЕДИА» АҖ ФИЛИАЛЫ ҖИТӘКЧЕСЕ –
БАШ МӨХӘРРИР ГӨЛНАРА ИЛЬЯС кызы САБИРОВА.

© Газетада басылган язмаларны файдалану, шулай ук өзекләр китерү өчен, «ШК» редакциясеннән язмача рөхсәт алу мәҗбүри. Редакциянең фикере авторларның фикере белән аваздаш булмаска да мөмкин. Редакциянең рәсми оешмаларда юллаучы булып йөрү мөмкинлеге юк. Кульязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый. Реклама һәм игъланнардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен аны бирүчеләр үзләре җаваплы.

РЕКЛАМА ХЕЗМӘТЕ
Тел: (843) 562–50–12,

ХАТЛАР БҮЛЕГЕ
Тел: (843) 562–50–03,
E–mail: shahri–kazan@tatmedia.com

НӘШРИЯТ
«Татмедиа» АҖ
420097, Казан, Академия ур., 2

16+
Сатудагы бәясе ирекле

Тираж – 6179
Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
Заказ 697. Газета Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек итү буенча Федераль хезмәттә (Роскомнадзор) 2012 елның 27 августында ПИ №ФС77–50970 нче теркәлү таныклыгы алды. Газета атнага 3 тапкыр – сишәмбе, пәнҗешәмбе һәм җомга көннәрендә чыга. График буенча бу санга 17 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 17 сәгатьтә.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ
420066, Казан,
Чистай ур., 5 нче йорт
Тел.: (843) 562–50–12,
факс: (843) 562–50–07

БАСМАХАНӘ
420066, Казан, Декабристлар ур., 2 нче йорт.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел–Пресс» полиграфия–нәшрият комплексы